ЯРДӘМ ӨЧЕН

Россиядә мохтаҗ кешеләр реестры төзеләчәк

> 6

УЕННАН УЙМАК

Җәй житкәч, балаларга игътибарны тагын да арттырырга туры киләчәк

> 15

ГОМЕРЛЕК ҮКЕНЕЧ

Россиядә абортларны түләүле итәргә жыеналар

> 16

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 73 (29040) | Җомга | 26 май | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

vk.com

СУСАУ

КЛИМАТ ҮЗГӘРЕШЕННӘН НӘРСӘ КӨТӘСЕ?

Кайвакыт безгә һава торышы акылдан шашкан кебек тоела. Ялтырап кояш чыгасы урынга бозлы яңгыр ява, һава басымы бер көнне өскә сикерсә, икенче көнгә бөтенләй түбәнгә тәгәри, бер тамчы яңгыр төшмәгән чаклары да, давыллап, чиләкләп коеп үткән вакытлары да була. Быел майда җәй челләсен күзәтәбез. Синоптиклар да барысы беравыздан, җылынабыз, ди. Алга таба ни көтәсе? Климат нинди үзгәреш кичерә? Белгечләр белән шул хакта сөйләштек.

> 7

Ишетми калмагыз

Мәктәпне уңышлы тәмамлаучыларга янә көмеш медальләр тапшырыла башлаячак. ТАСС хәбәренә караганда, үзгәреш яңа уку елыннан кертелә. Көмеш медаль тапшыру федераль дәрәҗәдә 2014 елда туктатылды. Элек ул урта мәктәпне тәмамлаганда ике «дүртле»се булган укучыларга бирелә иде.

Хезмәт дәресен дә кире кайтармакчылар. Мәгърифәт министры Сергей Кравцов ТАСС хәбәрчесенә белдергәнчә, ул технология дәресеннән аерылачак. «Бездә цифрлы технология дәресенә өстәмә булып, технология дәресе керә. Ә менә хезмәт дәресендә без балаларга үз куллары белән нәрсәләрдер ясап, үзләрен күрсәтү мөмкинлеге бирәчәкбез, бик мөһим бу», – дигән ул.

Исегезгә төшерәбез: бер төркем депутатлар, мәктәп укучыларын, яше һәм сәламәтлегенә карап, җәмгыять өчен файдалы хезмәткә җәлеп итүне күздә тоткан закон проектын Дәүләт Думасына кертькән.

Нурлат районы хакимияте башлыгы Алмаз Әхмәтшин Смоленск өлкәсе губернаторы урынбасары вазыйфасына күчә. Бу җәһәттән кабул ителгән карар Смоленск өлкә Думасы утырышында бертавыштан килештерелгән. Әхмәтшин яңа вазыйфасында төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, транспорт, энергетика, тариф сәясәте, төзелеш күзәтчелеге һәм мәдәни мирас мәсьәләләрен хәл иту белән шөгыльләнәчәк.

Алмаз Әхмәтшин 2008–2010 елларда Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Әйләнә-тирә мохитне саклау департаментына җитәкчелек итте, министрның инвестицион-инновацион эшчәнлек буенча урынбасары булды. 2010–2016 елларда төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары булып эшләде. 2018 елдан Нурлат районына җитәкчелек итте.

Татарстан приставлары май аенда бурычлылардан 44,5 миллион сум салым түләткән. Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча Баш идарәсе хәбәренә караганда, пристав бурычлының мөлкәтенә арест та салырга мөмкин. Бу мөлкәттән файдалануны чикләү яки тыю, шулай ук аны тартып алуны аңлата.

Шул рәвешле приставлар май аенда салым түләмәүчеләрнең 500 мөлкәтенә арест салган.

Татарстанда һава торышы үзгәрә. Эссе, коры һаваны якын көннәрдә явым-төшемле, җилле һава алыштырачак. Гидрометеоүзәк хәбәренә караганда, шимбә һәм якшәмбе – 27–28 майда кыска вакытлы яшенле яңгыр, көчле җил көтелә. Көндез +24...+29, көнчыгыш төбәкләрдә +32 градуска кадәр эссе. Төнге сәгатьләрдә исә термометрның терекөмеш баганасы +14...+19 градуска кадәр төшәчәк.

Синоптикларның башлангыч мәгълүматларына караганда, дүшәмбе – 29 майда һава температурасы кимеп, көндез +21...+26, төнлә +11....+16 градус тәшкил итәчәк. Шулай ук яшенле яңгырлар явып үтәчәк.

Районнарда ни хәлләр?

Арча

Район суды Шәке авылында яшәүче умартачы Нурулла Закиров файдасына карар чыгарды. Ул, узган елның июлендә кырларны химик матдәләр белән эшкәрткәннән соң бал кортлары үлү сәбәпле, «Северный» хуҗалыгы белән судлашкан иде. Хәзер Нурулла Закиров зыян өчен компенсация ала алачак. Министрлык агротехник эшләрне башкарганда барлык инструкцияләрне һәм таләпләрне төгәл үтәргә киңәш итә. Бал кортлары агулану билгеләре барлыкка килсә һәм билгеләнгән кагыйдәләрне бозу очраклары ачыкланганда район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә хәбәр итәргә кирәк.
(Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат хезмәте)

Тукай

Район мәктәпләреннән 80 укучысы җәйге каникулда «Ярыш», «Сәйдәш», «Гигант» һәм «Кама Беконы» кебек оешмаларга эшкә урнашачак. Шулай ук алар өчен җәй көне башка авыл җирлекләрендә дә эш урыннары бар. Авыл җирлекләрендә эш табылмаса, Тукай районының мәшгульлек үзәге һәр укучы белән аерым эшләячәк.
(«Якты юл»)

Сарман

Сарман урта мәктәбе укучысы Айгөл Вәлиева «Татарстанның Мини-мисс – 2023» исеменә лаек булды. Бәйгенең финалында республиканың төрле районнарыннан 30 кечкенә кыз очрашты. Айгөл 6 яшеннән Сарман сәнгать мәктәбенең «Умырзая» хореографик ансамблендә шөгыльләнә, күп тапкырлар илкүләм һәм халыкара бәйгеләр лауреаты булды. Әтисе Марат белән әнисе Раушания кызларын кечкенәдән милли рухта тәрбияләләр. Вәлиевләрнең гаиләсе иҗадилыгы белән танылды.
(«Сарман»)

Ютазы

Урыссу бистәсендә гомер кичерүче Нәгыймә Абдулманова 102 яшен тутырды. Урыссу бистәсендә яшәүче Нәгыймә әби, бер гасырдан артык гомер кичерсә дә, саулыгыннан зарланмый, тормышны, кешеләрне ярата, хәтере нык аның. Тумышы белән ул Башкортстанның Борай районындагы Кодаш авылыннан. Хезмәтне озын гомернең төп сере дип саный. Игелекле булырга, кешеләргә ярдәм итәргә һәм ачу сакламаска киңәш итә.
(«Ютазы таңы»)

Чирмешән

Чирмешән лицее мобилизацияләнгәннәргә ярдәм итү өчен игелек ярминкәсе оештырды. Әлеге акциядә укытучылар, әтиәниләр дә актив катнашты. Кемдер камыр ризыгы пешергән, теккән, чиккән, тозлаган, консервлаган. Товарларның күбесе төрелгән, бизәлгән, этикеткаларына кадәр ябыштырылган, бәясе күрсәтелгән. Игелек ярминкәсендә 201 мең сумлык товар сатылган. Бу акча махсус хәрби операциядә катнашучыларга җибәреләчәк.
(«Безнең Чирмешән»)

РӘИСТӘН БЕР КИҢӘШ

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов республиканың торак-коммуналь хуҗалык тармагының иң «авырткан җир»ен әйтте. Ул – коммуналь инфраструктураның тузуы. Шуңа күрә дә алдагы ике елда әлеге максаттан тармакка 8,6 миллиард сум акча бүлеп биреләчәк.

«Татар-информ»

Татарстан Министрлар Кабинетында республиканың ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекс оешмаларының 2022/2023 еллар ягу сезонында эш нәтиҗәләренә багышланган киңәшмә узды. Аны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үткәрде.

Татарстан төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры Марат Айзатуллин сүзләренә караганда, узган ягу сезоны 247 көн дәвам иткән. Кем әйтмешли, елның өчтән ике өлешендә мич якканбыз. Җылылык сезоны барышында республикада коммуналь хезмәт күрсәтүне туктатып торуга китергән 3160 авария очрагы теркәлгән. Аларның 7,5 проценты гына (237 очрак) җылылык белән тәэмин итүгә туры килгән. Гадәттән тыш хәлләр күбесенчә су белән тәэмин итүгә бәйле кыенлык аркасында килеп чыккан.

– ТКХ тармагында аварияга китерүче төп сәбәпләрнең берсе – инженер челтәрләренең канәгатьләндерерлек хәлдә булмавы. Татарстанда 23119 чакрым су үткәрү челтәрләренең – 32 проценты, 3106 чакрым җылылык челтәрләренең 35 проценты тузган һәм яңартуны таләп итә, – диде министр.

Ягу сезонында иң күп аварияләр теркәлгән шәһәр һәм районнарны да әйтте ләр. Кара исемлеккә Казан, Чаллы шәһәрләре, Азнакай, Бөгелмә һәм Яшел Үзән районнары эләккән. Марат Айзатуллин коммуналь инфраструктурасы начар хәлдә булган районнарны да атады. Бу хакта сөйләшкәндә, Рөстәм Миңнеханов Әгерҗегә аерым тукталды.

– Сез бит вазгыять кайда катлаулырак икәнен белеп торасыз, – дип мөрәҗәгать итте ул киңәшмәдә катнашучыларга. – Коммуналь инфраструктура ташландык хәлгә җиткәнче көтәргә кирәкми. Тузган хәлдәге объектлар ышанычлы түгел икәне аңлашыла. Аннары кыш көне әлеге кимчелекләрне төзәтергә туры килә.

Бу җәһәттән, Рәис киңәшмәдә катнашкан «Татэнерго» оешмасы генераль директоры Рәүзил Хаҗиевка эш тә кушты.

– Әгерҗене үз канатыгыз астына алыгыз. Якташларыгызга мөмкин кадәр ярдәм итегез. Эшләгән чорда җитәкче исемен алтын хәрефләр белән язарлык яхшылыклар эшләп калдырырга киңәш итәм, – диде Рөстәм Миңнеханов, уенын-чынын бергә кушып.

Киңәшмәдә хәбәр итүләренчә, алдагы ике елда Татарстанда коммуналь инфраструктураны яңарту өчен 8,6 миллиард сум акча бүлеп биреләчәк.

– Коммуналь хуҗалык объектларының торышы ил күләмендә төп проблемаларның берсе булып санала. Шуңа күрә Россия Президенты Владимир Путин тарафыннан коммуналь инфраструктура объектларын яңартуга бәйле яңа программага старт бирелде, – диде Марат Айзатуллин.

Әлеге программа кысасында республикага ике елга 4,3 миллиард сум акча бүлеп биреләчәк дип көтелә. Моннан тыш, республика бюджетыннан да финанслау каралган.

«Сетевая компания» җәмгыятенең генераль директоры Илшат Фәрдиевнең исә – үз баш бәласе. Җитәкче яңа төзелгән сәнгать мәйданнары һәм социаль биналарда электр челтәрләренең тиешенчә файдаланылмавыннан зарланды. Башта бертөрле саннар күрсәтәләр дә аннары әлеге егәрлекнең яртысын да кулланмыйлар, дип сөйләде ул.

– Мондый күпертелгән саннарны кайдан алалар соң? – дип аптыравын яшермәде Рәис. – Моның өчен дәүләт түли бит. Электр челтәрләренең эшен тәэмин итеп торырга да кирәк. Ә артык егәрлекле чыбыкларны карап торудан ни файда?

Рәис коммуналь хезмәтләр өчен түләү мәсьәләсен дә күз уңыннан ычкындырмаска киңәш итте.

– Кибеттә акчасыз бер кирпеч ипи дә бирмиләр. Шуңа күрә ут һәм су өчен дә вакытында түләргә кирәк, – диде Рәис.

Монысы инде бөтен республика халкына кагылды.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ПУТИННАН РӘХМӘТ

Россия Президенты Владимир Путин Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүне оештырган өчен рәхмәт белдерде.

«Миңнеханов Рөстәм Нургалиевичка Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздырудагы казанышлары өчен Россия Федерациясе Президенты рәхмәтен белдерергә», – диелгән документта.

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү чаралары ел буе дәвам итте. Аның кысасында быел федераль дәрәҗәдә оештырылган KazanSummit форумы, «Изге Болгар җыены» һәм башка зур чаралар узды.

ЗАМАНЧА НИЯТ

Пилотсыз очкычлар өчен батарея, диодлы яктырткычлар, «акыллы» видеокүзәтү камералары... Якын киләчәктә «Иннополис» махсус икътисадый зонасында әнә шундый мөһим әйберләр җитештерә башлаячаклар. Махсус икътисадый зонаның Күзәтчеләр советы утырышында шундый 10 проект тәкъдим ителде.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов уздырган. Утырышта тәкъдим ителгән барлык проектлар да хуплау тапты. Сәнәгать тармагы һәм IT оешмалар тарафыннан эшләнгән әлеге проектларның гомуми инвестиция күләме 3 миллиард сум тәшкил итә. Алар ярдәмендә 784 яңа эш урыны булдырырга җыеналар.

Утырыш дәвамында 6 оешма махсус икътисадый зона резиденты исеменә лаек булды. Аларның һәркайсы бирдә зур эшләр башкармакчы. Әйтик, «Батареон» оешмасы «Иннополис»та пилотсыз очу аппаратлары, элемтә чаралары, медицина җиһазлары, робот техникасы җитештергәндә кулланылучы аккумулятор-батареялар чыгарырга җыена. «Тулпар Интерьеры Инжиниринг Дизайн» оешмасы исә бирдә су, һава һәм җир өсте транспорты өчен кирәк-ярак әзерләүче комплекс төземәкче. Резидент дип танылган тагын бер оешма – «Рейлюкс» ҖЧҖ «Иннополис»та диодлы һәм бактерицид яктырткычлар җитештерергә ниятли. Тагын өч оешма бирдә мәгълүмат эшкәртү үзәге булдырырга, махсус программалар эшләп чыгарырга җыена.

Утырышта тагын дүрт оешма «Иннополис» махсус икътисадый зонасының партнеры дип танылды. Шуларның берсе – «ДиджиталАутоСистемс» оешмасы бирдә сәнәгать өчен роботлар җитештерергә теләи. «МСК ГРУПП ИС» ҖЧҖ исә үзендә ясалма интеллект мөмкинлекләрен туплаган видеокүзәтү камералары чыгарырга планлаштыра. «Нтех Лаб» оешмасы кешенең йөзен танып белү проектын гамәлгә ашырмакчы.

БУЛГАННЫ БЕЛЕП ТОТАСЫ

tatarstan.ru

Авыл кешесен ничек эшле дә, ашлы да итәргә? Республиканың көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгышындагы 14 районның башлыклары, авыл җирлеге, шәхси ярдәмче хуҗалыклар һәм гаилә фермалары җитәкчеләре шул хакта фикер алышты.

Менделеевск районында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров, Җирле үзидарә органнары ассоциациясе советы рәисе Әгъзам Гобәйдуллин катнашында узган зона семинар-киңәшмәсендә икмәк һәм сөт бәясе турында да сөйләштеләр.

Мондый очрашулар инде 15 нче мәртәбә оештырыла. Быел ул Менделеевскидан тыш, Зәй, Югары Ослан һәм Балык Бистәсе районнарында да уза. Максаты – проблемаларны ачыклап, мөмкинлекләрне барлау. «Безнең уртак бурыч – авыл кешесенең активлыгын үстерү, аларның табышын арттыруга ярдәм итү. Хәзерге шартларда авыл хуҗалыгы икътисадның төп тармакларының берсенә әверелә, ә азык-төлек иминлеге – ил суверенитетының нигезе», – диде Фәрит Мөхәммәтшин киңәшмәдә.

Парламент башлыгы чыгышында узган ел 5 млн тоннадан артык ашлык җыеп алынуын, республикада савылган сөтнең беренче мәртәбә 2 млн тоннадан артып киткәнен искә төшерде. Авыл хуҗалыгы продукциясе күләме 334 млрд сумга җиткән. Моның өчен ул авыл хуҗалыгында эшләүчеләргә рәхмәт белдерде.

Республикада 470 меңнән артык шәхси ярдәмче хуҗалык, 4 меңгә якын фермер хуҗалыгы, күпсанлы шәхси эшкәртү предприятиеләре эшли, Татарстанда җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясенең якынча 40 проценты алар өлешенә туры килә. «Болар барысы да дәүләт программаларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә мөмкин булды», – диде Фәрит Мөхәммәтшин һәм җирле түрәләргә эш кушты: нинди мөмкинлекләр барлыгын халыкка җентекләп аңлатырга кирәк.

– Бу юнәлештә тырышыбрак эшләргә кирәк. Чөнки, банк кредитларыннан аермалы буларак, шәхси хуҗалыкларга, гаилә фермаларына һәм КФХларга бүлеп бирелгән бюджет акчасы кире кайтарылмый. Бу акча фермерның үзенә дә, авылга да, тулаем районга да эшләячәк, – диде ул. – Татарстанда дәүләт ярдәменең тулы бер системасы эшләнде. Федераль һәм республика программаларында язылган ярдәм чараларыннан мөмкин булганча файдаланырга өйрәнергә кирәк.

Әмма эшләгәнне аш итәсе дә бар әле. Шуңа күрә киңәшмәдә икмәк һәм сөткә бәяләр төшү турында да сөйләштеләр. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, республика җитәкчелеге бу проблеманың барлыгын белә. Әйтик, федераль үзәк белән – ашлык экспортлау пошлиналары, ә республикада элеваторлар, йөк төяү станцияләрен төзү һәм модернизацияләү, логистиканы җайга салу юнәлешендә эш алып барыла. Парламент башлыгы фикеренчә, эшкәртүне арттырырга, өстәмә кыйммәтне республикада калдырырга кирәк. Ә фермерларны кооперативларга берләшергә чакырды ул.

Марат Җәббаров авыл эшкуарлыгын үстерүдә проблемалы мәсьәләләрнең берсе дип быелның беренче кварталында шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сыерларның баш саны кимүен атады. «Бу мәсьәләдә бернинди аклану да була алмый. Барыбыз да республиканың азык-төлек иминлеген һәм авыл халкының мәшгульлеген тәэмин итү өчен эшлибез», – диде ул.

Тонна һәм центнерларга гына түгел, авылның киләчәгенә дә кагылышлы зона семинар-киңәшмәсенең тагын берсе Зәй районында Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов катнашында узды.

– Барысы да чагыштыруда күренә. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, эш графигы тыгыз булса да, районнар буенча еш йөри. Татарстан Республикасы, аның җитәкчелеге өчен шәһәр һәм авыл бер бөтен организм хасил итә. Бу яктан республикада авыл мәнфәгатьләрен кайгыртучы дистәләгән программа эшли. Ләкин, кызганычка, бездә авылны саклар өчен күп эшләр башкарылса да, урбанизация авыл тормышына зур йогынты ясый. Нинди генә программалар булса да, авылдан халыкның китүен туктатып булмый, авыллар картая, – диде ул. – Ләкин, икенче яктан, ниндидер зур масштаблы бурычлар турында сөйләү дә дөрес булмас иде. Махсус хәрби операция бара, ил икътисады кысылды, федераль бюджет зыян күрде. Республика җитәкчелеге көн саен бурычлар һәм төрле проблемаларны хәл итү өчен тырыша. Ләкин хәтта бу вазгыятьтә дә республика икътисады тотрыклы булып калды, узган еллардагы ярдәмне саклап калырга тырышты. Шуңа күрә безгә тагын да нәтиҗәлерәк, оешканрак һәм җаваплырак булырга кирәк. Бу шартларда илдәге вазгыять өчен җаваплылык безнең проблемалардан өстенрәк.

Сан

✓ **2022** елда шәхси ярдәмче хуҗалыкларда **107,3** млрд сумлык авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерелгән. Бу – алдагы елдан **3,9** процентка күбрәк.

✓ **2015** елдан башлап **2591** шәхси ярдәмче хуҗалык **624,2** млн сумлык субсидия алган.

✓ Ел йомгаклары буенча, шәхси ярдәмче хуҗалыкларда терлек саны **511** сыерга арткан.

КУРКЫНЫЧ ЯНӘШӘДӘ

Моңа кадәр күпчелек очракларда кош гриппын кыргый үрдәкләр йоктырса, хәзер вирусның акчарлаклардан күчүе билгеле булган. Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Габделхак Мотыйгуллин журналистлар белән очрашуда әнә шулай дип белдерде.

– Үрдәкләр, вирус таратса да, үзләре һәлак булмый иде. Быел без башка хәл күзәтәбез, – диде белгеч. – Акчарлаклар күпләп үлә. Кош гриппының барлык очракларында да диярлек вирус чыганагы – акчарлаклар. Ни өчен авыруның аларга күчүен федераль үзәк өйрәнә. Якын киләчәктә бу сорауга җавап булыр, дип өметләнәбез.

Белгеч сүзләре буенча, быел кош гриппыннан 50 ил зыян күргән. Алар арасында Россия дә бар. Быел безнең илдә авыруның 37 очрагы теркәлгән. Шуларның 18е – Татарстан белән чиктәш төбәкләрдә. Аерым алганда, Мари Илендә – 4, Удмуртиядә – 5, Киров өлкәсендә – 9. Нәкъ менә Удмуртиядә акчарлакларның күпләп үлүе билгеле булды.

– Хәзерге вакытта авыру күршедәге Мари Иле, Удмуртия республикаларында һәм Киров өлкәсендә бар. Бу безне бик нык борчый, авыру янәшәдә генә йөри дигән сүз, – ди Габделхак Мотыйгуллин.

Татарстанда шәхси хуҗалыкларда һәм сәнәгать комплексында 18 млн кош бар.

– Күбесе – 15 миллионы – кошчылык белән шөгыльләнүче компанияләрдә үрчетелә. Фермер хуҗалыкларында 2 млн кош булса, шәхси хуҗалыкларда – 1,5 млн. Шуңа күрә Татарстанга кош гриппы кебек авыру керү аеруча куркыныч, – диде Габделхак Мотыйгуллин.

Белгеч тагын бер тапкыр саклану чаралары турында искәртте.

– Беренчедән, сатучыдан, һичшиксез, ветеринар белешмәсе сорарга кирәк, – диде ул. – Анда уздырылган барлык тикшеренүләр дә, шул исәптән кош гриппының булу-булмавы да күрсәтелә. Икенчедән, документсыз авылга кертмәскә кирәк. Өченчедән, документлар тәртиптә булып, кошларны алган очракта да, үлү очраклары булса, шунда ук ветеринарларга хәбәр итү мәҗбүри.

Әйтеп кенә бактым

Ызгыш

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Шифаханәгә киткәндә, дөнья мәшәкатьләреннән бераз котылып торырмын дип уйлаган идем, барып чыкмады. Беркөнне телевизорны ник кабызуыма үкендем. Бер украин хатынының үз баласына нинди тәрбия бирүен күрсәттеләр. Баласына ике-өч яшь чамасыдыр, каршына, үзе әйтүенчә, рус курчагын куя да аны ничек кыйнарга икәнен өйрәтә бу. «Башына менә шулай сугарга кирәк!» – ди. Сабый, тырыша-тырыша, аның хәрәкәтләрен кабатлый.

Дөресен әйткәндә, баштарак мин әлеге сюжетны гади бер саташу дип кабул иттем. Әмма Украина җитәкчеләренең: «Русларны Җир шарының теләсә кайсы ноктасында үтерәчәкбез», – дигән сүзләре искә төшкәч, уйга калдым. Бүген бөтен дөньясы саташа, кайчандыр фашизмга каршы көрәшкән илләрдә башка милләт вәкилләрен кешегә санамаган яңа буын тәрбияләнә.

Күптәнге бер вакыйга искә төште. Казан телестудиясендә эшләгән чак. Миңа Мәскәүдә, радио-телевидение хезмәткәрләренең Бөтенсоюз институтында гыйлем эстәп, һөнәри осталыгымны арттырырга насыйп булды. Осталыгым ни дәрәҗәдә камилләшкәндер – анысын әйтә алмыйм, ә менә шул елларда без, илнең төрле почмакларында яшәүче тележурналистлар, СССРның төрле милләт халыклары өчен тату бер гаилә икәненә ышана идек. Бер-береңә кимсетеп карау, авыр сүз әйтү юк иде институтта. Әйе, юк иде, әмма бер көнне…

…Без яшәгән тулай торакта бердәнбер душ бүлмәсе бар иде, шуңа күрә юынып чыгар өчен кайчак чират җиткәнен көтәргә туры килгәләде. Әмма без аны артык мәшәкать дип кабул итмәдек, зарланмадык.

Беркөнне коридорда ямьсез итеп кычкырган тавыш ишетелде. Берәү: «Шакшылар, пычрагыгызны юып бетерә алмыйсыз…» – дигән сүзләр әйтеп, кемнедер эттән алып, эткә салып сүгә иде. Коридорга чыксак, Киев телевидениесеннән килгән Елена, такмаклый-такмаклый дигәндәй, душ бүлмәсе ишеген шакый, аягы белән типкәләп ала. Менә юыну бүлмәсе ишеге ачылып китте дә, аннан Элиста телевидениесендә эшләүче ике калмык кызы килеп чыкты. Еленага бер сүз дә дәшмәделәр алар, тиз-тиз атлап, бүлмәләренә кереп киттеләр. Икенче көнне институтта гыйбрәтле җыелыш узды. Калмык кызлары Еленаның кыланмышлары турында институт җитәкчелегенә шикаять язган һәм җитәкчелек, Еленаны институттан куу мәсьәләсен төркемдәшләре хәл итсен дип, җыелыш уздырырга кушкан. Безнең төркем җитәкчесе Галина Анатольевна Галочкина үзе дә аптырашта иде. Моңа хәтле институт тарихында милли ызгышлар булмаган. Сүзен ничек башларга да белмәде Галина Анатольевна, сөйкемле йөзендә уңайсызлану чалымнары күренде. Бераз дәшми торды да: «Ну, что будем делать, ребята?» – диде. Берәү дә дәшми, калмык кызлары да, Елена да. Тулы бер халыкны «шакшы» дип ата әле син!

Шәхсән үзем Азәрбайҗан егете Гусейн Абдуллаев, Төрекмәнстаннан Рәфикъ Сеидов, Үзбәкстаннан Артын бәк, Таҗикстаннан Халикъ, Одессадан Саша, Мурманскидан Юра белән тәмам дуслашып-туганлашып аерылышкан идек. Бу исемлеккә тагын бик күпләрне өсти алам әле. Без телефоннар, адреслар алышып, бер-беребезгә кунакка йөрергә сүз куешып аерылыштык. Дөрес, бүтән күрешергә насыйп булмады, әмма аларның һәрберсен хөрмәт белән искә алам.

Без туган көннәрне, бәйрәмнәрне бергә уздыра идек, үз җырларыбызны җырлый идек. Миннән: «Риманчик, давай спой нам Яхина!» – дип сорыйлар иде. Рөстәм Яхинның Мостафа Ногман сүзләренә язган «Киек казлар» җыры һәрберсенә ошый иде. Бер-беребезнең җыр-көйләрен яраттык без егетләр белән, хәтта бер-беребезнең киемнәрен алмашып кия идек…

Бүген дөньяга ни булды? Кичәге дусларның кайберләре ни өчен дошманга әверелде? Совет чорындагы дуслык әкиятсез булмады микәнни? Аллаһы Тәгалә бар кешене тигез яраткан. Әмма җәмгыятьтән үсеш-үзгәрешләр бәндә баласын еш кына глобаль сәясәтнең корбанына әйләндерә. Шекспирга ияреп, «Тормыш – театр, без – анда артистлар», – диярғә яратабыз үзе, әмма артистланмаска, асылыбызга кайтып, яңадан үзебез булып калырга иде.

ҮЛГӘН СЫЕР СӨТЛЕ БУЛА

Соңгы айларда Арча район газетасы «Сердәшләр» дигән рубрикада бик гыйбрәтле һәм күңелне нечкәртә торган язмалар бирә башлады. Теләсәң, аларның һәркайсын бер роман яисә повесть итеп үстерергә мөмкин булыр иде. Мин үзем, мәсәлән, «Саклаучы фәрештә» дигән хикәямне шундый язмаларның берсеннән этелеп китеп яздым. Интернетта алган кайтавазларга караганда, хикәя укучыларны да дулкынландырды шикелле. Дөрес, укылышлы булу, әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше яхшы дигәнне аңлатмый әле. Тик шулай да…

Менә бу язмага да этәргечне танылган журналист, бай тәҗрибә иясе һәм сирәк очрый торган акыл белән бүләкләнгән Ильяс абый Фәттахов «Күзләрдә яшьләр кипкән иде…» дигән язмасы бирде. Язманың каһарманы Бөек Ватан сугышы башланган елда туып, тормышның байтак кына сикәлтәләрен үткәннән соң, утыз яшендә Алабугада милиция мәктәбе тәмамлаган һәм Арча районына лейтенант званиесендә 75 сумлык оклад белән эшкә урнашкан. Язма йотылып укый торган бик күп фактларга ия булса да, минем компьютер (баш миен әйтүем) шул 75 сум дигән санда эленеп калды.

Соңгы вакытларда бездә совет чорын, аның тотрыклылыгын, түбән бәяләрен һәм башка уңай якларын өзелеп сагыну киң таралды. Хәзерге капитализмның талаулы бәяләре, көн саен кесәдәге акчаны очсызландыра торган инфляциясе, процентлы кредитлары кешеләрнең бик җелегенә үтте. Шуңа күрә «үлгән сыер сөтле була» дигән кагыйдә буенча, өзелеп үткәннәрне сагыну бер дә гаҗәп түгел. Хәзерге пропаганда да моны бик оста эксплуатацияли, халыкның үткәннәргә бәйле татлы сагышта яшәвеннән сәяси дивидендлар алырга тырыша.

Тик шулай да, әйдәгез, объектив булырга омтылыйк. 1971 елда бер балалы гаиләсе булган милиция офицерының тормышының матди дәрәҗәсен ачыкларга тырышыйк. Бер нәрсәне искәртәбез: җитмешенче еллар – совет чорының иң тотрыклы, матди югарылыкларга ирешкән чагы. Ул чакта әле кибетләрдәге дефицит та алтмышынчы еллар яисә бигрәк тә сиксәненче еллар белән чагыштырырлык түгел. Нәкъ менә шул чорны ык үскән социализм дип тамгаладылар да инде. Сиксәненче еллар башында тормыш бик тиз артка чигә башлады һәм ун ел тирәсе вакыт эчендә система җимерелеп тә төште.

Совет чорында иң тотрыклы бәя арыш икмәгенеке иде. Бер ипи – 16 тиен. 14 тиенлек буханка да авылга сирәк булса да кайтарыла, әмма авызга алырлык түгел. Милиция офицеры окладына ул чакта 469га якын буханка икмәк сатып алып булган. Хәзерге полицейскийларның окладын мин белмим. Татарстандагы минималь хезмәт хакын гына алам. Арыш ипиенең дә бәясе бик төрле, әмма Татарстанда уртача бәя бер икмәккә (600 грамм) 35 сум чыга. Бездә 2022 елда бюджеттан тыш тармакта минималь хезмәт хакы 16 мең 700 сумга җиткән икән. 2023 елда 19,5 меңгә җитәсе ди. 16,7 меңне 35кә бүләбез дә 477,14 дигән сан килеп чыга. Хмм… 1971 елдагы милиция офицеры окладына караганда хәзерге минималь хезмәт хакы бу җәһәттән караганда өстенрәк булып чыга бит әле монда. Минималь хезмәт хакын Татарстандагы уртача ит бәясенә бүлсәк тә (475 сум), 35 килодан артык килеп чыга. Сүз уңаеннан, мин үзем декабрь аенда 430 сумнан саттым итне. Милиция офицеры окладына 1971 елда (ул чакта Казанда талон юк иде дип әйтәләр, дөрес булса) шуннан аз гына күбрәк ит алырлык булган. Офицерның хезмәт хакы хәзерге минималь хезмәт хакы белән генә ярыша бит әле монда.

Ильяс абый язмасының персонажы участок милиционеры булып эшли башлагач, аңа йөрергә ат биргәннәр, әмма аның белән мәшәкать килеп чыгу сәбәпле, ул атны ташлап, җәяү йөри башлаган. Әгәр ул үз акчасына автомобиль сатып алырга теләсә, ничә ай эшләр иде икән, санап карыйк әле. 1971 елда ВАЗ-2101 автомобиленең бәясе 5150 сум торган. Лейтенантның хезмәт хакы белән ул акчаны бер дә башка нәрсәгә тотмыйча җыйсаң, 68,66 ай (5,66 ел) җыярга кирәк булган. Бездә совет чорында инфляция юк дип санала, әмма җитмешенче еллар уртасында ВАЗ-2101 инде 5500 сум тора, димәк, арткан бәя лейтенантның тагын алты айлык хезмәт хакын соры. Газетада эшли башлагач, мин дүрт кешелек гаиләне тәэмин иткән хәлдә, ел ярымнан аз гына артык акча җыеп, өр-яңа «Калина» (ВАЗларның онысы) алдым.

Әмма тагын бер нәрсәне әйтмичә булмый. Шуны әйтмәсәк, яшьләрдә ялгыш фикер туарга мөмкин. Совет чорында автомобильнең бәясе бар, әмма үзе… юк иде. Бик кысылып һәм озаклап акча җыйгач та, сатып алу өчен тагын да озаграк чират торырга кирәк. Кайберәүләр ул чиратны көткәндә, СССР таралып та өлгерде, машиналык һәм берничә машиналык акчалар Саклык банкында сагылып калды. Акча җыйган кайберәүләр «ычкынды» шул чакта, «түбәләре кыйшайды». Үзүзләренә кул салучылар, эчкечелеккә бирелүчеләр күп булды. Бик авыр мирас калдырды совет чоры туксанынчы елга барып җиткән кешеләргә.

АКШ Президенты Рональд Рейган яратып сөйли торган бер анекдот чынбарлыктан артык ерак тормый иде. Рейган исә болайрак сөйли: «СССРда автомобиль сатып алу өчен, аванс түләп, ун ел чиратта торырга кирәк. Һәм менә бер сатып алучы аванс кертә, аңа: «Булды, ун елдан соң машинагызны алырга килерсез», – диләр. «Иртәнме, көндезге яктамы?» – дип сорый теге. «Ун елдан соң иртә белән көндезнең ни аермасы бар?» – диләр. «Иртән сантехник килергә тиеш иде», – ди мескен». Анекдот инде бу, билгеле. Әмма сантехник чакырып, өйгә китертү совет чорында могҗизага тиң иде. Үзең ремонтлап куйыйм дисәң, су краны табу сантехник китертүдән дә кыенрак. Хәер, ул вакытта краннар бик гади иде. Мин үзем, резиннан кисеп «прокладка» ясап, бер генә кран ремонтламадым. Авыл өендә краннар да бик юк иде инде, чөнки су кермәгән, бәдрәф урамда…

Менә боларны искә алсак, совет чорының матди тормыш дәрәҗәсендә сагынырлык нәрсәләр бик юк иде үзе. Маршрут автобусына бер аяк белән эләксәң, Арчага 30 километрны бер сәгать газап эчендә бара идең. Колеялы таш юлдан шыплап тулган автобус бик әллә ни кызу элдерә алмый иде. Үзбушаткыч йөк машинасының кузовында утыз градус салкында җилләп кайту (җил синең аша үтәли йөри андый вакытта, кузовта үзең генә булмыйсың, бер-береңә сыенып җылынасың) бер дә гаҗәп тоелмый иде.

Совет чорында хөрлек, ирек тә бик юк иде. Рәсми рәвештә иң ирекле, иң гадел ил – совет иле дигән пропаганда каннарга сеңгәнче үткәрелде. Пропагандистлар үзләре дә аңа бик ышанып бетмиләр иде, билгеле. Рабинович турындагы анекдот белән иллюстрацияләп була ул чактагы пропагандага ышанычны. «Рабиновичны капиталистик илгә командировкага җибәрәләр. Бераздан ул җитәкчеләргә «Мин ирекне сайладым» дигән кыска гына телеграмма юллый. (Хәзерге яшьләр телеграмманың нәрсә икәнен аңлыйлармы икән соң? «Телеграм» белән бутамыйлармы икән?) Хезмәт коллективында шунда ук партия җыелышы җыялар. Ватанны саткан Рабиновичны камчыларга һәм нәтиҗәләр ясарга ниятлиләр. Җыелышның уртасында Рабинович килеп керә. Тынлык урнаша. Ниһаять, ул: «Минем телеграмманы ничек аңлавыгыз миңа бик кызык тоелды», – ди.

Укучылар дөрес аңласыннар: автор һич кенә дә хәзерге чорга мәдхия җырларга теләми. Хәзерге тәҗрибә белән совет чорына кайтсак, без, мөгаен, законны бозмыйча гына ничек акча эшләргә, ничек автомобиль алырга икәнлеген белер идек. Бар иде аның мөмкинлекләре, бар иде. Совет кешесенең күпчелеге аларны файдалана гына белмәде. Әйтәләр бит әле: «Гомереңахырына якынлашканда, син аны ничек башларга кирәк булганын аңлыйсың», – дип. Чынлап та, шулай ул. Совет кешесендә әчкерсезлек, самимилек көчле иде, бар нәрсәне дә акча белән бәяләү гадәте юк иде. Килешик: сагынырлык нәрсәләр болар. Темага күп нәрсә язарга ниятләгән иде автор, әмма мәйдан беткән икән инде.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Эльвира
ВӘЛИЕВА

«ПАРАЛЛЕЛЬ» ДӨНЬЯ

Әле кайчан гына көнкүреш техникасын сайлаганда «Samsung», «LG», «Bosch» ише чит ил брендлары кәттә булып саналса, бүген сатучылар «Атлант», «Sonik», «Midea» кебек җитештерүчеләрне мактый. Кибет киштәләре икегә бүленгән: бер якта – безнекеләр, икенче якта – параллель импорт. Чит илдән кайтарылган телевизор, суыткычларны алучы бармы? «Параллель импорт» тамгасы сугылган кер юу машинасы сатып алганда ничек алданмаска? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

Бер «яшь»лек импорт

– Бүген генә ике телевизор, бер микродулкынлы мич саттым, – ди башкаладагы көнкүреш техникасы кибетләренең берсендә эшләүче Марат Гыймадиев. – Узган елгы кыенлыклардан соң, ниһаять, зур кибетләр җанлана башлады. Без көн дәвамында сигез-ун консультант эшлибез. Элек сатып алучыларга ярдәм итәргә өлгермәсәк, хәзер кергән бер кеше артыннан йөрибез. Халык безгә акрынлап килә башлады. Дөрес, күбрәк арзанлы товарларга өстенлек бирәләр. Кибет киштәсендә үзебездә һәм безгә дустанә мөнәсәбәттә булган илләрдә җитештерелгән көнкүреш техникасы да, параллель импорт буенча кайтканы да бар. Тик соңгысына шикләнеп карыйлар.

Рәсми мәгълүматларга караганда, былтыр илдән 500гә якын чит ил компаниясе киткән яки вакытлыча эшен туктаткан. Кибетләр бушап калмасын өчен, узган ел Россиядә параллель импорт гамәлгә керде дә инде. Моңарчы рәсми дилерлар чит ил брендларын Россиягә җитештерүче яки товар билгесен куллану хокукына ия булучының рөхсәте белән генә алып кайта ала иде. Ә параллель импортта мондый ризалык кирәкми. Товарны арадашчы ролен үтәүче өченче илләр аша алып кайталар. Бу хәзер Россиягә урау юллар аша чит илдән теләсә нәрсә кайтарырга ярый дигән сүз түгел, әлбәттә. Рөхсәт ителгән товарларның аерым исемлеге бар. Ул илнең Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан төзелгән һәм даими үзгәртелеп тора. Параллель импорт буенча кертелгән барлык товарлар да оригиналь һәм сертификатлы булырга тиеш. Россиядә ул 2023 елның азагына кадәр гамәлдә булачак.

– Көнкүреш товарларына ихтыяҗ арту ул – әлбәттә, икътисадның яхшыруы билгесе, – ди Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов. – Тик Татарстанстат мәгълүматларына караганда, куллану базары үсеш кичерми әле. Без артка тәгәрәүдән генә туктадык. 2023 елның гыйнвар – март айларын узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, куллану базары азрак, тәгаен әйтсәк, 0,3 процентка кимегән. Быелның апрель – май айларында көнкүреш техникасы һәм электроникага бәяләр бераз төшү дә әлеге базарны җанландырып җибәрде. Моңа соңгы арада фатир һәм йортларда ремонт ясаучылар арту да өлеш керткән, дип уйлыйм. Агымдагы елның беренче яртысында торак төзүчеләр – 8,6, ә булганын ремонтлаучылар 37 процентка арткан.

> Өлешчә мобилизация игълан ителгәч, халык, акчасын әрәм-шәрәм итмичә, саклап тота башлаган иде. Бүген исә без акрынлап кесәдәге акчаны кирәк-яракка файдалануга күчәбез.

Белгеч әйтүенчә, узган елның июнь азагыннан гамәлгә кергән параллель импортның тәүге нәтиҗәләре билгеле инде.

– Көнкүреш техникасы өлкәсен алсак, 2022 ел йомгаклары буенча илдә барлык сатылган смартфоннарның 19 проценты, ноутбукларның 41 проценты параллель импортка туры килгән. Былтыр параллель импорт буенча 1,5 миллиард долларлык смартфоннар һәм ноутбуклар сатылган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Чаллыда эшләнгән

Тик параллель импорт базарының икенче ягы бар: теге яки бу бренд илдән чыгып киткән икән, димәк, аның продукциясенә җитештерүчедән гарантия дә калмый. АКШ Үзбәкстанга дип җитештергән суыткыч бездә ватылса, «параллель» техниканы Үзбәкстанга илтәсеме? Бу сорауны кибетчеләргә бирдек.

– Бер дә гарантиясе булмаган товарлар юк, әлбәттә, – ди «Ситилинк» интернет-кибетләр челтәренең гарантия мәсьәләсенә бәйле сораулар буенча белгече Людмила. – Бездә, мәсәлән, товарга гарантия вакыты аның кайсы фирманыкы булуына бәйле. Мисал өчен кер юу машинасын алыйк. Хәзер «Samsung»ка бер ел гарантия бирелә. Россиядә аның техник хезмәт күрсәтү (сервис) үзәкләре эшли әле. Гарантияне дә алар бирә. Ә менә «LG»га шулай ук бер ел, әмма кибет гарантиясе генә каралган. Техника сатып алганнан соң ике атна эчендә ватылса, элеккеге тәртип буенча, аның акчасын кайтарырга яки шундый ук төзек товарга алмаштырырга мөмкин. Әгәр күңелсез хәл ике атна үткәннән соң килеп чыга икән, кер юу машинасын сервис үзәгенә алып китеп төзекләндерәчәкләр. Иң күп гарантия үзебездә һәм безгә дустанә мөнәсәбәттә булган илләрдә җитештерелүче техникага бирелә. Мәсәлән, Белоруссиядән кайтартылган «Атлант» яки Кытайның «Centek» кер юу машиналарына гарантия вакыты – өч ел.

Көнкүреш техникасы кибете хезмәткәре Марат Гыймадиев әйтүенчә, параллель импорт буенча кайткан товарларның кимчелекле яклары шактый.

– Чит илләр аша товар алып кайту кыйммәткә төшә. Шуңа күрә безгә техниканың искергән модельләрен җибәрәләр. Мәсәлән, моннан өч-дүрт ел элек үк сатуга чыккан «Samsung» кер юу машинасы Кытайда җитештерелүче яңа буын «Midea» техникасы белән бер үк бәя – 50 мең сум тирәсе тора. Әмма соңгысы күпкә заманчарак. Ул керне пар белән дә юа, машина барабанын үзе чистарта. Безгә дустанә мөнәсәбәттә булган илләрдән кайткан яңа брендлар әлегә чагыштырмача арзан. Тик бу вакытлыча гына. Хәтерләсәгез, заманында «Haier» көнкүреш техникасы да очсыз иде. Моннан ике-өч ел элек 30–35 мең сум торган кер юу машиналары бүген 70 мең сумлык чикне дә узып китте инде. Өстәвенә «Haier» үзебездә – Чаллыда чыга. Параллель импорт буенча кайткан көнкүреш техникасына бер ел гарантия бирелә. Сервис үзәкләре запас частьларны Үзбәкстаннан кайтарта. Димәк, техника ватылса, төзекләндергәнне озак көтәсе була.

Акчалы җир буш тормас

«Параллель» товарларның кыйммәткә төшүен башкалада узган «Россия – Ислам дөньясы: «KazanForum»да Татарстан Сәүдә-сәнәгать палатасы рәисе Шамил Агеев та билгеләп үтте. Җыенда хәбәр итүләренчә, Пакьстан Татарстанда спорт товарлары җитештерә башлаячак. «Республикада мондый товарларга ихтыяҗ бармы?» – дип кызыксынды журналистлар.

– Бүгенге шартларда теләсә нинди сәнәгать отышлы. Күреп торасыз, параллель импорт кыйммәтләнә. Чөнки аның бәрабәренә арадашчылар кесә калынайтып калырга тырыша. Шуңа күрә үзебездә мөмкин кадәр күбрәк сәнәгать булдырырга кирәк, – диде Шамил Агеев.

Бу көннәрдә параллель импорт исемлеген кыскартырга җыенулары да билгеле булды.

– Ихтыяҗ булган товарларга гына параллель импорт булырга тиеш, – дип белдерде Россия сәнәгать һәм сәүдә министры Денис Мантуров. – Шуңа күрә җитештерүче рөхсәтеннән башка илгә кертелүче брендлар исемлеге кыскарылачак. Ул моңарчы да өч тапкыр оптимальләштерелгән иде инде. Безнең төп бурычыбыз илдәге җитештерүчеләргә уңайлы шартлар булдырудан гыйбарәт.

ТОВАР «УПКЫН»ЫННАН КОТЫЛДЫК

Параллель импорт буенча кайткан товарларга гарантия бирүнең хокукый яклары һәм әлеге төр продукциянең әһәмияте турында «ВТ» хәбәрчесенә Интернет-сәүдә компанияләре ассоциациясе рәисе Артем СОКОЛОВ сөйләде:

– Параллель импорт буенча кайткан товарларга гарантия һәм аның вакытына бәйле сораулар канун нигезендә билгеләнмәгән. Шуңа күрә узган ел сәүдә эшенең сыйфатын саклап калу өчен, Интернет-сәүдә компанияләре ассоциациясенә керүче оешмалар үзләре альтернатив юл белән кайтарылган товарларга бер ел гарантия бирү тәкъдиме белән чыкты. Ул хәзер дә үз көчендә. Товарга гарантия бирү күзлегеннән караганда, сатып алучы өчен телевизор яки чәйнекнең кибеткә кайсы юл белән кайтып җитүендә берниндиә дә аерма юк. «Кулланучылар хокукларын яклау турында»гы закон һәркем өчен бер үк. Ритейлерларга (ваклап сатуны оештыручы компанияләр. – **Ред.**) исә эшләренә үзгәрешләр кертергә туры килде. Шул исәптән илгә теге яки бу товарны керткәндә, аңа гарантия бирү һәм сервис хезмәте күрсәтүгә киткән чыгымнарны да исәпкә алалар. Эш шунда ки, параллель импорт очрагында, әгәр сүз илдән киткән брендлар турында бара икән, гарантия хезмәте элеккеге кебек җитештерүчедән түгел, ә сатучы кесәсеннән башкарыла.

Ничек кенә булмасын, параллель импорт механизмы узган җәй ахырында кайбер төр товарларга барлыкка килгән кытлыкны юкка чыгарырга ярдәм итте. Кибет киштәләрендә Россия һәм БДБ илләрендә җитештерелгән продукция артса да, безне товар «упкын»ыннан нәкъ менә параллель импорт коткарды. Аңа бүген дә ихтыяҗ бар. Моның өчен интернет-кибетләрнең сайтларына кереп карау да җитә.

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

ӨЛЕШЕҢӘ ТИГӘН КӨМЕШЕҢ

РОССИЯДӘ МОХТАҖЛАР РЕЕСТРЫ БУЛДЫРЫЛА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ил хөкүмәте мохтаҗлар реестры булдырырга җыена. Бу исемлек чын мәгънәсендә мохтаҗ кешеләрне билгеләү өчен кирәк дип аңлаталар. Шул рәвешле, булышсыннар иде дип өмет иткән кешеләрне барлап, хөкүмәткә аларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү дә җиңелрәк булачак дип фаразлана.

Кем син, мохтаҗ кеше?

Әле күптән түгел генә «ВТ» хәбәрчесе Россиядә фәкыйрьләр саны азайган, дип, ярлыларның киму сәбәпләрен ачыклаган иде. Социаль түләүләр өлеше 20,6 проценттан 20,7 процентка кадәр, эшкуарлык эшчәнлегеннән кергән керемнәр 5,5 проценттан 6,2 процентка кадәр артканы билгеле. Ярлыларның кимүенә шулай ук балалы гаиләләргә каралган ярдәм чараларын арттыру һәм эшсезлек дәрәҗәсенең түбән булуын да сәбәп итеп күргән иде белгечләр.

Саннарны тагын бер тапкыр хәтердә яңартып үтик:

Росстатның соңгы мәгълүматлары буенча, илдә фәкыйрьләр саны 10,5 процентка (15,3 млн россияле) калган иде. Бу күрсәткеч яңа Россия тарихында иң түбәне булып санала. Татарстан буенча яшәү минимумы 13319 сум тәшкил итә. Бу – хезмәткә яраклы кешеләр өчен. Пенсионерларга – 10508 сум, балаларга – 11852 сум. Россия күләмендә түбәндәгечә: эшкә яраклы халык өлешенә 15669 сум тия, пенсионерларга – 12363 сум, балаларга – 13944 сум.

Россиядә фәкыйрьлек дәрәҗәсе ничек үзгәргән?



Чыганак: Росстат

Мохтаҗларны барлау, аларга ярдәм итү турында бер генә тапкыр сөйләнмәде инде. Әйтик, Россия Премьер-министры вазыйфасын биләгән чагында Дмитрий Медведев «фәкыйрьләр портреты»н төзергә тәкъдим иткән иде. Аерым бер кешегә аерым ярдәм кирәк, дигән фикердә торган иде Премьер. Яңасе, кешегә булышу өчен аның тормыш хәленең үзенчәлеге, ихтыяҗлары, белеме, мөмкинлекләре, хәтта сәламәтлеге дә исәпкә алынырга тиеш.

Иске яңа тәкъдимне шушы көннәрдә илнең вице-премьеры Татьяна Голикова телгә алды. Мохтаҗлар реестрын 2024 елның гыйнварыннан эшләтеп җибәрергә телиләр. «2023 ел өчен мөһим максат бу. Без инде бу проектны гамәлгә ашыру вакытын бер мәртәбә кичектергән идек. Әзер булмавыбыздан түгел, ә реестрны эшләтеп җибәрү өчен башка мәсьәләрне дә хәл итәргә кирәк булганга шулай эшләдек», – диде Татьяна Голикова. Аның сүзләренчә, бу эш кемнең ярдәмгә мохтаҗ булуын билгеләргә һәм җыйган мәгълүматны Росстат күрсәткечләре белән чагыштырырга мөмкинлек бирәчәк.

Сүз уңаеннан, 2022 ел нәтиҗәләре буенча, Россиядә мохтаҗлар саны дүрт төбәктә арткан иде. Адыгея, Ингушетия, Тува һәм Хакасия турында сүз. Фәкыйрьлекне киметүгә Карачай-Черкес, Калмыкия, Төньяк Осетия, Коми, Оренбург өлкәсе һәм Ненец автономияле округы да ирешә алмаган.

«ВТ» юристы Булат Закиров аңлатканча, хәзерге вакытта Россия законнарында «мохтаҗ» дигән бердәм төшенчә юк. Аларны билгеләгән вакытта төрле сәбәпләрдән чыгып эш итәргә мөмкиннәр.

– Мәсәлән, кемдер мохтаҗ гражданнарның кереме МРОТтан (минималь хезмәт хакы күләме) азрак тәшкил итә, дип саный. Әмма МРОТтан югарырак керем, мәсәлән, кешенең торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булмавын аңлата алмый. Шуңа бәйле рәвештә, «мохтаҗ» төшенчәсен билгеләү өчен конкрет өлкәдә конкрет законнарны карарга кирәк, – ди юрист.

Булат Закиров искәрткәнчә, Россиядә социаль ярдәм чараларының төрле программалары гамәлгә ашырыла: торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларга ярдәм итү, торак биналарына мохтаҗларга ярдәм итү, даими карауга мохтаҗларга ярдәм итү һәм башкалар.

– Соңгы вакытта мохтаҗларны комплексны билгеләү күзәтелә – бу мохтаҗны билгеләгәндә керем дәрәҗәсе генә түгел, ә берничә фактор анализлана дигәнне аңлата (авырулар, милек булу һ.б.). Әйтелгәннәрдән чыгып, яңа мохтаҗлар реестрына социаль ярдәм яки дәүләт тарафыннан бирелә торган ташламалар таләп ителгән барлык кешеләр керәчәк дип фаразлый алам, – дигән фикердә белгеч.

Фикер

**Николай КУЛЬБАКА,
икътисад фәннәре кандидаты:**
– Хәзерге фәкыйрьлек белән СССР чорындагысы нәрсә белән аерыла? Беренчедән, СССР таркалганнан соң утыз елдан артык вакыт узды, ә бу – зур вакыт аралыгы. Элек булмаган яңа технологияләр барлыкка килде, күп кенә төр продукцияне җитештерү дә күпкә арзанрак. Мәсәлән, бик бай булмаган кеше дә хәзер Россиянең теләсә кайсы почмагы белән видеоэлемтә аша тоташу мөмкинлегенә ия. Ә бу 80 нче елларда хәтта Совет элитасының югары катлавы өчен дә мөмкин хәл түгел иде. Массакүләм җитештерү нәтиҗәсендә, совет кешеләренә хас булган кием һәм аяк киеме дефициты хәзерге икътисадта мөмкин дә түгел. Азык-төлек җитештерү белән дә шулай. Нәтиҗәдә Россия кебек илдә массакүләм ачлык һәм фәкыйрьлек була алмый.
(«Российская газета»)

Нәтиҗәсе булырмы?

Кушылучыларның урыннарын алмаштырудан гына сумма үзгәрми. Бәйсез финанс консультанты Шамил Муталовның хакимият тәкъдименә карата фикере шундыйрак. Белгеч әйтүенчә, фәкыйрьлек, мохтаҗлык проблемасы ярлыкны башка төрле формула буенча санау ысулы белән генә хәл ителә торган эш түгел.

– Фәкыйрьләр, мохтаҗлар бөтенләй юк дигән нәтиҗәгә килерлек формула да уйлап табарга була ул. Әмма бу гына проблеманы хәл итмәячәк, – ди белгеч. – Банк картасына килә торган керем (хезмәт хакы, дивиденд һ.б.) түгел, ә барлык чыгымнардан соң калган мая күләме мөһимрәк. Әйтик, айга 500 мең сум эшләргә һәм шул ук сумманы сарыф итәргә дә була. Биш елдан соң бу кешенең капиталы нульгә тиң булачак. Финанс ягыннан грамоталы кешене карыйк. Әйтик, укытучы. Ул аена 20 мең сум ала, ди. Ул, финанс ягыннан белемнәрен кулланып, барлык чыгымнардан соң да кеременең 10 процентын булса да янга калдыра алса, шул ук биш елда 120 мең сум акча эшли алыр иде. Инвестицияләргә тотса, кесәсенә тагын да күбрәк акча кертә ала. Мондый реестрны кирәк дип тапмыйм. Халыкны акчасын дөрес тотарга өйрәтергә кирәк. «Фәкыйрьләрчә» фикерләүне дә үзгәртәсе иде. Финанс буенча грамоталылыкка өйрәтү авыр түгел. Бу белемнәрне кулланып, кеше тормышындагы мохтаҗлык кебек күренешләрне юк итә алыр иде. Хөкүмәттән, фондлардан, иганәчеләрдән бирелә торган «күчтәнәч»ләргә генә ышанып ятмасын иде кеше. Моның өчен, әйтүемчә, фикерләү рәвешен дә үзгәртергә кирәк.

Психология фәннәре магистры, психолог Чулпан Нигъмәтҗанова-Гарәфиева әлеге мәсьәләнең аңга һәм кешенең психологик халәтенә тәэсир итә торган ягына игътибар юнәлтте.

– Реестр, бәлки, чынлап та, мохтаҗларны барларга һәм ярдәм кирәк кешеләргә вакытында булышырга мөмкинлек бирер. Моның уңай ягы да бар. Психология ягыннан карасак, әлбәттә, бик күпләр үзләрен фәкыйрь, мохтаҗ итеп тануларын теләмәс иде. Шәхес буларак, алар үзләрен башкалардан түбән санауларын көтми, – дигән фикердә белгеч.

Чулпан сүзләренчә, медальнең ике ягы булган кебек, бу мәсьәләнең дә уңай һәм тискәре нәтиҗәләре булырга мөмкин.

– Мохтаҗлар һәм мохтаҗ булмаганнар дигән бүленеш барлыкка килгәч, бу, әлбәттә, реестрда булган кешеләрнең үз-үзләренә түбән бәя бирүенә, үз-үзләренә ышаныч югалуына, үзләреннән һәм үзләре кебекләрдән оялуга китерәчәк. Мондый исемлектә булу үзбәягә бик тә тәэсир итәчәк, – диде белгеч. – Киресенчә дә булуы бар: кайберәүләр, бу исемлеккә эләкмәс өчен, күбрәк эшләргә, тормышта максат табарга, үзләрен камилләштерергә тырышмагае.

«Татар-информ»

СУСАУ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Җылынабыз

КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы мөдире, профессор Юрий Переведенцев иң элек климатның һәм һава торышының аермасын аңлатып бирде.

– Климат ул – билгеле бер төбәкнең уртача күпьеллык һава торышы, ә һава торышы ул – атмосфераның нәкъ менә хәзерге вакытта булган халәте, – диде ул. – Климат һәрвакыт үзгәреш кичерде, ләкин соңгы 100 елда ул аеруча сизелерлек. Планетада уртача еллык температура +15 градусны тәшкил итә. Ә Россиядә температура нибары 4 градус кына. Татарстанда уртача еллык температура +5 градус тирәсендә тирбәлә. Кайвакыт 6, 7 градуска кадәр җитә. Планета белән чагыштырганда, ул кадәрле зур да түгел. Бездә иң уңайлы һава торышы булып чыга.

КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы карамагындагы метеостанция 1813 елдан бирле күзәтүләр алып бара. Ул вакытта Казанда уртача еллык температура 2 градус кына булган. Димәк, климатның глобаль җылынуы – хак сүзләр. Белгеч тә, соңгы ун елда җылыну бик тиз бара, дип аңлатты.

Күзәтүләр Татарстанда һава температурасының иң зур тизлек белән гыйнвар аенда үсүен күрсәткән. Уртача алганда, ун елга 1 градусны тәшкил иткән. Әгәр мондый тизлек башка айларда да дәвам иткән булса, XXI гасыр ахырына температура 7 градустан артып китәр иде.

Белгеч сүзләренчә, планетада климат җылынуга беренче чиратта антропоген факторлар (парник эффекты) йогынты ясый. Атмосферага чамадан тыш күп газлар бүленеп чыга, сәнәгать предприятиеләре эшләп тора, халык саны арта. Боларга тагын Кояш активлыгы, Җирнең магнит кыры үзгәрү, вулканнар ату да өстәлә.

– Бу мәсьәлә бөтен кешене борчый. Дөнья күләмендә зур җыелышлар уздыралар, килешүләр төзиләр. Әгәр планетада уртача еллык температура тагын 1,5 градуска күтәрелсә, сәяси-икътисадый югалтулар күп булачак. Климат шартлары авыл хуҗалыгына, энергия җитештерүгә, транспорт, төзелеш һәм башка тармакларга йогынты ясый. Ул шулай ук кешеләрнең сәламәтлегендә дә чагылыш таба. Дөнья океаны биеклеге арта, димәк, кайбер илләрнең су астында калу куркынычы бар. Кайбер илләрдә, киресенчә, коточкыч корылык булырга, янгыннар башланырга мөмкин. Хәзерге вакытта Себердә янгыннар котыра. Бу да – климат җылынуның аяныч нәтиҗәсе, – ди белгеч.

Юрий Переведенцев әйтүенчә, климаттагы үзгәрешләр тиз һәм агрессив рәвештә бармасын өчен, һәрдаим мониторинг алып барырга, күпчелек тармакларда һава шартларына җайлашырга, электр энергиясеннән азрак файдалану ысулларын кулланырга, углекислый газны һавага чыгаруны киметергә кирәк.

Ышаныргамы, ышанмаскамы?

Берничә көн элек кайбер матбугат чараларында, быел 150 ел эчендә иң эссе җәй көтелә, дигән хәбәр басылып чыккан иде. Тик озак та узмыйча, Гидрометеоүзәктә моны кире кактылар. Ни өчен еш кына һава торышы буенча фаразлар дөреслеккә туры килми соң? Юрий Переведенцев моның сәбәбен аңлатты.

– Ул махсус математик модельләр ярдәмендә фаразлана. Һава торышын фаразлар өчен, мәгълүматлар булырга тиеш. Алар бөтен Җир шарыннан, шул исәптән спутниктан да җыела. Алар ярдәмендә һава торышын 3–5 тәүлеккә кадәр төгәлрәк фаразларга мөмкин. Ә менә озак вакытка фаразлау бик кыен. Шулай ук явым-төшемнәрне дә алдан әйтү иң читене. Бер карашка, һава торышы җиңел генә формалаша кебек тоелса да, ул – бик катлаулы процесс, кайберләре хәтта бүгенгә кадәр өйрәнелмәгән. Ул бик күп факторларга бәйле. Кояш радиациясе, дымлылык, температура, басым, җил... Аларның һәркайсы берберсенә йогынты ясый. Әйтик, температура үзгәреше һаваның дымлылыгына йогынты ясый ала, анысы исә, үз чиратында болытлар хасил итеп, яңгырлар яудырырга мөмкин, – ди ул.

Россия Гидрометеоүзәге җитәкчесе Роман Вильфанд та озак вакытка фаразлар әйтүнең ни дәрәҗәдә катлаулы эш булуын әйтә.

– Аларны төзи белергә, җитди фәнни басмаларда язмалар бастырырга, үз өстенә җаваплылык алырдай белгечләр кирәк. Тик алар бик аз. Бу бик зур белем таләп итә. Шуңа күрә әгәр сез озак вакытка нинди дер аномаль фаразлар күрәсез икән, күңелгә шунда ук шик керергә тиеш, – ди белгеч.

Юрий Переведенцев исә якын көннәргә фаразларын җиткерде. Метеостанция мәгълүматлары буенча, бу көннәрдә һава температурасы июльне хәтерләтте – 30 градуска җитте. Шимбә көнне исә ул бераз төшәчәк. Майга хас булмаганча җылы булса да, кайбер районнарда яңгырлар булырга мөмкин.

– Бу бик яхшы булыр иде, чөнки илдә инде корылык башланды. Май һәм июньдә яңгыр булмау – иң начары. Бу айларда температура никадәр түбән булса, мул уңыш алу өчен шартлар шулкадәр зуррак була. Быел явым-төшем аз булу мине борчуга сала. Яз иртә килде. Хәзерге вакытта урамда – июль һавасы. Шулай да майда суыклар булып, үсемлекләргә, игеннәргә зыян салырга өлгерде. Майда һәрвакыт Арктик һава агымы күтәрелә. Быел да ул безне читләтеп узмады. Ул бик куркыныч, түбән температура алып килә, – дип аңлатты белгеч.

Кызыклы күзәтү

Татарстанда иң җылы еллар:

1973, 2010, 2016

ФОБОС һава торышы үзәгенең әйдәп баручы белгече Евгений Тишковец сүзләренчә, тагын бер төбәкнең уртача күрсәткечләре елдан-ел үзгәрә.

– Безне әле эсседән суыкка ташлый, корылыктан – көчсез яңгырларга. Кызганыч, мондый көйсез һава торышы алдагы елларда да дәвам итәчәк. Һава торышы фаразларына килгәндә, озак вакытка фаразларның 60 проценты гына туры килә, калган 40ы – хата, – ди ул.

Корылык көчәя

Арча районының баш агрономы Әхмәт Хәкимҗанов әйтүенчә, климат үзгәрүен авыл хуҗалыгы тармагында да тояллар.

– Бер ел икенчесенә охшап килми. Бер елны язгы кыр эшләренә иртәрәк тотынсак, икенчесендә эшләр соңрак башлана. Ләкин соңгы берничә елда корылык артты. Вегетация чорында явым-төшемнең кимүе күзәтелә. Безнең зона болай да корылардан санала. Табигатьнең үзгәреше эссе коры елларда бөҗәкләр активлашуыннан да сизебез. Яңа төр корткычлар килеп чыга, күбәя. Моннан тыш, һава торышына бәйле, орлыкларны да үзгәртергә туры килә, – диде ул.

Әхмәт Хәкимҗанов әйтүенчә, көзге культуралар башка елларга караганда начаррак тишелгән.

– Көзен тишелеп, дым җыеп калыр өчен, дым аз булды. Язын арыш, бодайлар бик әйбәт, тармаклану фазасында. Әлегә дым да җитәрлек. Май башларында матур гына яңгырлар да явып узды. Безнең җирлектә игеннәргә зыян салырлык суыклар булмады.

Сынамышлар сыната

Синоптиклар халык сынамышларына да артык ышанмаска киңәш итә. Бигрәк тә соңгы елларда табигать шулкадәр тиз һәм нык үзгәреш кичерә ки, сынамышлар күпчелек очракта бөтенләй дөрес булмый, ди алар. Бу фикерне халык синоптигы Рәис Шәкүров та раслады.

– Мин озак еллар табигать күренешләрен дәфтәремә язып барам. Моннан берничә ел элек шуларга нигезләнеп, алдагы көннәргә, айларга фаразлаган һава торышы туры килеп бара иде. Хәзер үзем дә буталып бетәм, чөнки алдагы елларга нигезләнү катлаулана. Табигать саташты, дип йөрим инде мин. Әйтик, май, минем фаразлар буенча, салкын һәм яңгырлы булырга тиеш иде. Суыклары булып алды, тик яңгыры юк. Май башындагы карларны көткән идем. Чөнки кышын гыйнвар – февральдә кар яумады, күз ачкысыз көчле буран булмады. Шулар җәен булачак. Безнең якларда берсе булды инде, җәен тагын көчле яңгырлары, җилләре, гарасатлары белән сынарбыз, дип уйлыйм. Табигать барыбер үзенекен кабатлый.

Климатның җылынуга таба баруын халык синоптигы да инкарь итмәде.

– Язлар елдан-ел иртәрәк килә, табигатьтәге үзгәрешләрне сизми калу мөмкин түгел. Башка елларда сыерчык баласын 23 июньдә очыра торган иде, быел бер ай алдан очтылар. Быелгы ел 1973 елга охшап тора. Ул ел да шундый эссе, коры иде. Быел да шундый ук җәй булыр, дип уйлыйм. Майда ук 30–31 градус эссе булгач инде... Быел каргаларның бик аз килүе дә гаҗәп булды, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Белгеч фикере

Евгений ТИШКОВЕЦ, ФОБОС һава торышы үзәгенең әйдәп баручы белгече:

– Климат үзгәрешенә бәйле берничә рәсми фараз бар. Имин булган очракта, климат җылыну аркасында, Дөнья океаны 40 сантиметрга күтәреләчәк һәм җитди су басулар булачак. Ә инде иң кара фаразлар буенча, 100 елдан соң Җир өслеге чүлгә әвереләчәк. Ләкин мин моңа ышанмыйм, чөнки мондый фаразлар белән БМО шөгыльләнә, ә анда сәясәткә урын бар. Мин хәзер глобаль климат акрынлап тигезләшә дип саныйм. Һәм, һәрвакыттагыча, глобаль җылынудан соң глобаль суыну килә. Кешеләрне климатик апокалипсислар белән куркытырга кирәкми. Безгә бары тик үзгәрешләргә тыныч кына җайлашырга өйрәнергә кирәк.

«Вечерняя Москва» басмасына биргән әңгәмәсеннән

29 май | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» Телесериал 16+
10.00, 23.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.40 «БОМБА». Телесериал (на татарском языке) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Каравай» 6+
16.30 «Гаилә учагы» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00, 00.45 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
22.10 «Реальная экономика» 16+
00.20 «Соотечественники». Органическая химия и органичные Арбузовы 16+
01.15 «Вечерняя игра» (2017) 16+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КУНАК АШЫ – КАРА-КАРШЫ, ЯКИ КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». Телевизион нәфис фильм 16+
15.25, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Үткәннәр сагындыра» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ТРЕЙДЕР» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу. 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ПАРОМЩИЦА. ДОЛИНА МЕЧТЫ» 12+
23.25 «Вечер» 12+
02.05 «МОСКОВСКАЯ БОРЗАЯ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
06.30 «Здоровый образ. Баскетбол» 12+
07.00, 12.55, 14.55, 19.40 Новости
07.05, 15.30, 16.40, 17.40, 18.40, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.55 Футбол. Турнир развития УЕФА. Россия – Киргизия. Прямая трансляция из Волгограда
12.00 «Вы это видели» 12+
12.35 Специальный репортаж 12+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.25 «Магия большого спорта» 12+
15.00 «География спорта. Ростов-на-Дону» 12+
15.55 Хоккей 3Х3. «Лига Ставок Кубок Минска». Россия (U20 красные) – Белоруссия (U20). Прямая трансляция из Белоруссии
16.55 Хоккей 3Х3. «Лига Ставок Кубок Минска». Россия (U20 белые) – Белоруссия (U21). Прямая трансляция из Белоруссии
17.55 Хоккей 3Х3. «Лига Ставок Кубок Минска». Матч за 3-е место. Прямая трансляция из Белоруссии
18.55 Хоккей 3Х3. «Лига Ставок Кубок Минска». Финал. Прямая трансляция из Белоруссии
19.45 «Громко». Прямой эфир
20.45, 05.00 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
21.45 Дартс. Профессиональная лига. Про Тур 3. Прямая трансляция из Москвы
00.55 Автоспорт. Российская Дрифт серия «Европа». Трансляция из Рязани 0+
02.00 Новости 0+
02.05 Фехтование. Международный турнир. «Московская сабля». Мужчины. Трансляция из Москвы 0+

НТВ

05.00 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 23.55 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 «ВОЕННАЯ ПОЛИЦИЯ» (S) 16+
22.10 Премьера. «ТРАССА СМЕРТИ» (S) 16+
03.40 Остросюжетный сериал «ЗАКОНЫ УЛИЦ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.30 «Давай разведёмся!» 16+
09.30 «Тест на отцовство» 16+
11.40 «Понять. Простить» 16+
12.55 «Порча». «Тёмная луна» 16+
13.25 «Знахарка» 16+
14.00 «Верну любимого» 16+
14.35 «Голоса ушедших душ» 16+
15.10 «ПОГОНЯ ЗА ТРЕМЯ ЗАЙЦАМИ» 16+19.00 «НЕВЕСТА». 1-я – 3-я серии 16+).
22.20 «ЛЮБЛЮ ОТЦА И СЫНА» 16+
02.00 «Понять. Простить» 16+
02.55 «Порча» 16+
03.20 «Знахарка» 16+
03.50 «Верну любимого» 16+
04.15 «КОЛЫБЕЛЬ НАД БЕЗДНОЙ» 16+
05.05 «6 кадров» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ТИХАЯ ЗАСТАВА» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
10.55, 01.20 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». Телесериал . «ГОД СОРОК ПЕРВЫЙ». 1-я серия 12+
12.35, 13.25 «Москва фронту». Документальный сериал 16+
14.00, 15.05 «КРАПОВЫЙ БЕРЕТ». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Битва за Россию». Документальный сериал. «Ледовое побоище. Александр Невский против Андреаса фон Вельвена». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «СЛЕДСТВИЕМ УСТАНОВЛЕНО» 12+
02.30 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 12+
03.50 «КРАПОВЫЙ БЕРЕТ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

30 май | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ». Телесериал 16+
10.00, 00.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». Телесериал (Россия) 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.40 «БОМБА». Телесериал (на татарском языке) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Соотечественники» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники». «С осколком под сердцем...» Герой Советского Союза Борис Кузнецов 16+
22.00 «Бәллүр каләм – Хрустальное перо 2023» 16+
01.20 «Видеоспорт» 16+
01.45 «Каравай». Народная песня – зеркало души 6+
02.10 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Вечерняя игра» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 18.20, 21.25 «КУНАК АШЫ – КАРА-КАРШЫ, ЯКИ КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». Телевизион нәфис фильм 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
22.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. «ТРЕЙДЕР». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Глафира Тарханова, Александр Ратников. «ПАРОМЩИЦА. ДОЛИНА МЕЧТЫ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «МОСКОВСКАЯ БОРЗАЯ» 16+
03.45 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Наши иностранцы» 12+
06.30 «Здоровый образ. Хоккей» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 17.50 Новости
07.05, 16.15, 20.00, 22.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25, 16.50, 05.00 Мировой футбол. Обзор 0+
11.25 Смешанные единоборства. UFC. Валентина Шевченко против Джессики Андраде. Трансляция из США 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
13.55 Хоккей. «Лига Ставок Кубок будущего». Россия (U20 красные) – Россия (U20 белые). Прямая трансляция из Белоруссии
17.55 «Магия большого спорта» 12+
18.25 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. Финал. «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону) – ЦСКА. Прямая трансляция
20.25, 23.55 Футбол. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. 1/8 финала. Прямая трансляция из Аргентины
23.00 Дартс. Профессиональная лига. Про Тур 3. Прямая трансляция из Москвы
02.00 Новости 0+
02.05 Фехтование. Международный турнир. «Московская сабля». Команды. Трансляция из Москвы 0+
03.05 Лёгкая атлетика. Мировой континентальный тур. Трансляция из США 0+

НТВ

05.00 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ВОЕННАЯ ПОЛИЦИЯ» (S) 16+
22.15, 00.00 Остросюжетный сериал «РЕАЛИЗАЦИЯ» (S) 16+
00.45 «ТРАССА СМЕРТИ» (S) 16+
03.25 «ЗАКОНЫ УЛИЦ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.20 «Давай разведёмся!» 16+
09.20 «Тест на отцовство» 16+
11.35 «Понять. Простить» 16+
12.50 «Порча». «Забыть» 16+
13.20 «Знахарка» 16+
13.55 «Верну любимого» 16+
14.30 «Голоса ушедших душ» 16+
15.05 «ТРИ ЛАНИ НА АЛМАЗНОЙ ТРОПЕ» 16+
19.00 «НЕВЕСТА». 4-я – 6-я серии 16+
22.20 «ЧУЖАЯ ЖИЗНЬ» 16+
02.05 «Понять. Простить» 16+
03.00 «Порча» 16+
03.25 «Знахарка» 16+
03.55 «Верну любимого» 16+
04.20 «КОЛЫБЕЛЬ НАД БЕЗДНОЙ» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «КРАПОВЫЙ БЕРЕТ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
10.55, 01.20 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». Телесериал. «ГОД СОРОК ПЕРВЫЙ». 2-я серия 12+
12.35, 13.25, 15.05 «ДАЛЕКО ОТ ВОЙНЫ». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Битва за Россию». Документальный сериал. «Куликовская битва. Дмитрий Донской против Мамая». Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «ИЖОРСКИЙ БАТАЛЬОН» 12+
02.30 «Гений разведки. Артур Артузов» 12+
03.15 «ДАЛЕКО ОТ ВОЙНЫ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе җитәкчесе урынбасары

ХӘБИБУЛЛИН
Алмаз Рәшит улының

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БАШЛЫККА БӘЙЛЕ ТҮГЕЛ

Россиядә менингитның катлаулы формалары белән авыручылар саны арткан. Роспотребнадзор идарәсе белгечләре моны пандемия тәмамланганнан соң карантин чаралары бетерелүгә бәйләп аңлата. Менингит кешедән кешегә йога аламы? Ул нәрсәсе белән куркыныч?

Казанның 21 номерлы шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты Регина ГАЛИУЛЛИНА шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Без менингит турында ниләр белеп торырга тиеш?
– Менингит – ялкынсыну рәвешендә уза торган җитди авыру. Аның вируслы, бактерияле, гөмбәчекле, катнаш төрләре була. Ул, нигездә, баш һәм арка миенә зыян сала. Бактерияле менингит белән авырып терелгән кешедә җитди өзлегүләр дә күзәтелергә мөмкин. Аерым алганда, кешене көзән җыера, ул начар ишетә, күзе күрми башларга, хәтере начарланырга мөмкин. Менингит олысын да, кечесен дә аямый. Шулай да ул балалар арасында күбрәк очрый. Ул һава аша йога. Аны китереп чыгарган В төркемле стрептококк эчәклек яки аналыкның лайлалы тышчасында да булырга мөмкин. Бала тапканда анадан балага да күчә ала.

:: Аның нинди билгеләре була?
– Менингит вакытында, иң беренче чиратта, муен мускуллары ката. Кешене бизгәк тота, зиһене чуала, психик халәте үзгәрә. Аның башы авырта, күңеле болгана башлый, коса.

:: Кайчан кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк?
– Әгәр тән температурасы 38–39 градустан югарырак күтәрелсә һәм аны беренче дару белән дә төшереп булмаса, чаң сугарга кирәк. Әгәр кешенең коскач та хәле рәтләнмәсә, бик нык башы авыртса, яктылыкка карый алмаса, кичекмәстән табибка барырга кирәк.

:: Менингиттан ничек дәваланыйлар?
– Дәвалау бары тик стационар яки реанимация шартларында гына булырга тиеш. Өйдә үзлегеңнән генә дәваланырга ярамый. Бактерияләргә каршы терапиядән тыш, менингит йоктырган кешегә вирусларга, туберкулезга каршы, баш һәм арка мие зарарланганда кулланыла торган дарулар бирәләр. Менингит җиңелчә формада узганда, кеше бик тиз терелә. Аның физик хәленә дә, психологик халәтенә дә зыян килми. Әлеге чир катлаулы формада узса, бик куркыныч. Ул хәтта инвалидлыкка, үлем-китемгә үк китерергә мөмкин.

:: Менингиттан үлү куркынычы ни дәрәҗәдә?
– Әгәр диагнозны беренче 12 сәгать эчендә куеп өлгерсәләр, әлеге чирдән үлем ихтималы 0,7–1,5 процентка гына кала.

:: Кыш көне башка киеп йөрмәсәң, менингит башланырга мөмкинме?
– Юк, бу – уйдырма. Ник дигәндә, менингит белән башлык кию-кимәү арасында бернинди бәйләнеш тә юк. Әлеге чир салкын йогынтысында пәйда булмый. Салкында туңсаң, иммунитет начарлана ала. Ә менә анысы менингитка сәбәпче булырга мөмкин.

МЕНИНГИТНЫ БУЛДЫРМАУ ӨЧЕН ТАБИБ КИҢӘШЛӘРЕ:
- салкында туңудан сакланыгыз;
- дөрес тукланыгыз, сәламәт яшәү рәвеше алып барып, спорт белән шөгыльләнегез, шул рәвешле иммунитетыгызны ныгытыгыз;
- вируслы менингиттан саклану өчен, гади генә гигиена кагыйдәләрен үтәргә (кулларны ешрак юарга һ.б.) кирәк;
- менингит белән авыручыдан ерак торыгыз;
- әлеге чир баш калкыткан чорда кеше күп җыелган урыннарда йөрүдән тыелып торыгыз;
- бактериаль менингиттан исә вакцина ясатып кына сакланып була.

Сорау – җавап

Балада остеопороз буламы?

? 15 яшьлек улым бер елда ике тапкыр кулын сындырды. Табиб, остеопороз, дип кисәтте. Ул өлкәннәрдә генә була түгелме соң?

Әлфия ХАРИСОВА. Казан

Табиб-травматолог Олег БРАГИН:
– Сөякләрнең ныклыгы турында яшьтән кайгыртырга кирәк. Балалар һәм яшүсмерләр остеопорозы да була. Кешенең сөяк системасы 30 яшькә кадәр формалаша. Активлык җитмәгәндә, ашказаны-эчәк тракты авырулары, дөрес тукланмау, тәмәке тарту хәлне тагын да катлауландыра ала. Баланың туклануына игътибарны арттырырга кирәк. Рацион фосфор һәм кальцийга бай булырга тиеш.

Белеп тор!

СЫР ТЕШНЕ НЫГЫТА

Сыр – аксым чыганагы. Аксым организмга яңа күзәнәкләр формалаштырганда кирәк. Сырдагы аксым тулысынча үзләштерелә. Анда аксым иттәгедән дә күбрәк. Ул йөрәк-кан тамырлары өчен дә файдалы. Авыруга бирешмәс өчен, көн саен бер кисәк сыр ашарга киңәш итеЛә. Моннан тыш сыр тешләрне кариестан саклавы, теш эмален ныгытуы белән дә игътибарга лаек. Ник дигәндә, ул фосфор, кальцийга бай. Кальцийга булган тәүлеклек ихтыяҗны канәгатьләндерү өчен 70 грамм сыр ашау җитә, ди белгечләр.

Табигать даруханәсе



ЧАГУ БЕЛӘН ГЕНӘ ТҮГЕЛ

Кычыткан А, B_2, С, D, К витаминнары, антиоксидант, аминокислота, хлорофиллга бай. Аңарда кальций, йод, калий, тимер, марганец та бар. Буыннар сызлавы, бөердә таш, сидек юллары авыруларыннан интегүчеләр өчен бер дигән сихәте бар. Кычыткканлы чәйләр ашкайнату трактын чистарта, иммунитетны күтәрә. Подагра, артрит, невралгия, радикулит кебек чирдән кычытканлы компресс кую файда бирә. Башта төнәтмәне әзерлибез: 200 г кычытканны банкага тутырырга һәм аңа 1 л аракы салырга. 24 сәгать буе аны кояшта, тагын бер атна караңгы урында тотарга кирәк. Төнәтмәне сөзеп, суыткычта саклау хәерле. Компресс болай ясала: җитен тукыманы кычыткан төнәтмәсендә чылатып, сызлаган урынга куеп торырга.

Файдалы

Каһвә гомерне озайта

Озак яшим дисәң, көненә ике чокыр каһвә эч! Америка галимнәре шундый ачыш ясаган. Алар 700 мең кешенең сәламәтлеген өйрәнгәннән соң, каһвә ир-ат һәм хатын-кызларның гомерен кыскартучы чирләр килеп чыгу ихтималын киметә, дигән нәтиҗәгә килгән. Моннан тыш көнөнә берничә чокыр каһвә эчкән кеше күңел төшенкелегенә дә сирәк бирешә икән. Галимнәр бу эчемлекнең картлык чорында еш күзәтелгән Паркинсон, Альцгеймер авыруларын кисәтүен дә ачыклаган.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

ҺӘР ЭШНЕҢ – ҮЗ ВАКЫТЫ

Җәй башында бакчачыларны соңга калмый башкарырга кирәкле күп кенә мөһим эшләр көтә. Кичекмәстән нинди эшләрне башкарырга кирәк соң?

Россельхозцентрның Татарстандагы филиалы җитәкчесе урынбасары Гүзәл ХӨСӘЕНОВА киңәшләрен бирде.

vk.com

ЧӘЧӘР ВАКЫТ

Хәзер кышка саклау өчен үстерелә торган чөгендерне чәчү, ә майда утыртылганнарын араларын 5 см калдырып сирәкләр вакыт. Моннан тыш, кәбестәнең соң өлгерә торган сортларын утыртыр чак та икәнен онытмагыз. Ике атна аралыгы белән тиз өлгерә торган яшелчә культуралары: шпинат, салат, редис та чәчсәгез була.

ПОМИДОРНЫ ОНЫТМА

Помидорны җентекләп карарга кирәк. Үги сабаклары вакытында өзү һәм бәйләү мөһим. Ике атна саен тирес яки кош тизәге эремәсе белән тукландырып, помидорга фитофторага каршы көрәш чараларын куллана башлар вакыт.

ИГЪТИБАРСЫЗ КАЛДЫРМА

• Әгәр дә крыжовник, кура җиләге куакларының очларын кисеп өлгермәгән булсагыз, моны хәзер эшләргә була. Кара карлыганның ботакларында кышлаган талпаннардан да арынырга онытмагыз. Куак талпан белән бик каты зарарланган очракта аны кисеп яндырыгыз хәерле.

• Җәйнең беренче аенда җимеш агачларын һәм куакларны тукландыру хакында онытмаска кирәк. Тукландыруны җимеш ярала башлауга башкарырга киңәш итәм. Аның өчен 1:2 өлеш исәбеннән тирес сыегы, 1: 8–10 өлеш сыер тизәгеннән ясалган ашлама (коровяк), 25–30 г аммиак селитрасы яки мочевинаны болгатып сибү файдалы. Һәр җимеш бирә торган крыжовник, карлыган төбенә әлеге эремәне 10 л, ә кура җиләге төбенә һәр метр мәйданга 5 л сибәсе.

• Июнь аенда алма һәм грушага күгәрек чиреннән (парша), ә крыжовникка ончыл чыктан саклау өчен чаралар кулланабыз. Агачларны карап, андагы үрмәкүч ояларын, бөтерелгән яфракларын, бөҗәкләрнең йомыркаларын җыеп алырга кирәк.

ГӨМБӘ АВЫРУЫННАН САКЛА

Гөмбә авыруларыннан саклау максатыннан, үсемлекләргә биологик фунгицидлар: Псевдобактерин-2, Ризопланга, бак катнашмасы (баковая смесь) микроашламалары (ГУМАТ+7 «Здоровый урожай»), Азолен микроашламасын кушып сибәргә мөмкин.

КЫРМЫСКА ҺӘМ БАШКАЛАР

Төрле корткычларга каршы сабын белән көл төнәтмәсе сиптерергә онытмыйбыз. Кырмыскаларның күп тупланган урыннарына яңа кайнап чыккан су сибегез. Гөбләләрдән котылу өчен тәмәке, көл-сабын эремәсе, шулай ук «Златогласка» һәм «Биостоп» препаратларын инструкциясендәгечә сибәргә мөмкин.

АЮЧИКЕРТКӘГӘ КӨН БЕТӘ

Корткычны кулга төшерү өчен, такта кисәкләреннән яшеренү урыны әзерләргә мөмкин, төнлә алар шуның астына җыелачаклар.

Аючикерткә өчен тозак та ясарга мөмкин. Пыяла банканың авызына бал сөртеп, аны муеныннан җиргә күмәргә. Банка авызын 1–1,5 см чамасы ярык калырлык итеп такта кисәге белән ябарга. Тозакка эләккән аючикерткә аннан чыга алмаячак.

Аючикерткә белән көрәшнең тагын бер ысулы – теплица кырыйларында ком белән керосин кушып ясалган бураэналар ясап чыккыгыз, аларның эзләре дә булмаячак.

Чүп үлән – җәфа да, файда да

Бакчада чүп үләннәрдән арынуга аерым игътибар бирергә кирәк.

✓ *аларны тамыр системасын көчәйтеп өлгергәнче җыярга киңәш ителә;*
✓ *утаганнан соң, чүп үләнне түтәлдә калдырмаска, җыеп алырга;*
✓ *яңгырдан соң утау яхшырак, үләннәр тамырлары белән җиңелрәк чыгачак;*
✓ *чүп үләннәрне котырып үскәч түгел, даими рәвештә утауны гадәткә әйләндерү кирәк;*
✓ *мулчә кулланыгыз, ул чүп үләннәр таралуга комачаулый;*
✓ *җирне яңа тирес белән ашларга тырышмагыз, анда хайваннар тукланган үләннәрнең орлыклары бик күп һәм алар бакчагызны басачак.*

Ашлама

Чүп үләннәрнең зыяны гына түгел, файдасы да бар. Алардан төнәтмә ясап, ашлама буларак кулланырга мөмкин. Мондый сыек ашламаның өстенлеге шунда: алар үсемлекләр тарафыннан тиз үзләштерелә, туфракның ачылыгын киметә һәм микроорганизмнарга баета. Шуны исегездән чыгармагыз: төнәтмә ясау өчен орлыгы өлгермәгән чүп үләннәрне генә кулланырга ярый!

Ризык

Чүп үләннәрнең киң таралганнарыннан берсе **КЫЧЫТКАН**ны кулинариядә дә кулланырга мөмкин. Мәсәлән, яшел щи пешерергә кузгалак урынына кычыткан салырга була, Аны кайнар су белән пешекләп, салат һәм соусларга да өстәргә мөмкин.

ТУЗГАНАК – иң татлы чүп үләннәрнең берсе. Аннан гомере әченә бер генә булса да кайнатма ясап карамаган кеше юктыр. Аның яфрагын, курыкмыйча, салатларга кушарга була.

БАКА ЯФРАГЫнда каротин, лимон һәм никотин кислотасы, фитонцидлар, дуплау матдәләре, С һәм К витаминлы, орлыгында тозлар һәм аксымнар бар. Аны салат ясаганда кулланырга мөмкин.

Тәмле булсын!

КОШ ТЕЛЕ

Гөлчәчәк ФӘТХУЛЛОВА рецепты

Кирәк: *4 йомырка (шуның берсенең сарысын гына кулланабыз), бер чеметем чәй содасы, ярты чәй кашыгы шикәр комы, он, ванильле шикәр пудрасы.*

Йомырка, чәй содасы, шикәр комын кушып яхшылап болгатканнан соң, онны аз-азлап салып, бик каты булмаган камыр басабыз. Өстен каплап, 15–20 минут ял иттергәннән соң, юка гына итеп җәеп, шакмакларга кисеп, кайнар майда кыздырып алабыз. Бик суынып өлгергәнче, ванильле шикәр пудрасы сибәбез.

ЭЛЕККЕЧӘ ПЕЧЕНЬЕ

Рәмзилә ХАҖИЕВА рецепты

Кирәк: *5 йомырка, зур бокал белән шикәр комы, 200 г атланмай, бер кечкенә кап көпшәкләндергеч, бер кап ванилин, кирәгенчә он.*

Һәммәсен кушып, үзегезгә кирәкле тыгызлыктагы камыр басыгыз. Тыгызрак камырны уклау белән җәеп, ә йомшагын кашык белән формага салып пешерәбез. Тыгызы кетерди торган була. Йомшаграк итим дисәгез, камырга онны азрак салыгыз.

Укучы киңәше

ТАШЛАРГА АШЫКМАГЫЗ

Майдагы салкыннарга кадәр помидорларымны рассадникка күчереп өлгергән идем. Тик 80 төпнең өчтән ике өлешен кырау сукты. Башта йолкып атарга дип уйлаган идем дә, бераз тотып торырга булдым. Зыян күргән үсентеләрнең күбесе эре помидор бирә торган сортлар иде. Тора-бара аларга бераз хәл кергән төсле булды, ә хәзер теге бөтенләй беткән инде дигәннәре дә яңарып, кырау тимәгәннәреннән дә көчлерәк булып утыралар. Шуңа күрә кырау сукты дип аларны йолкып атарга ашыкмагыз, тагын бер шанс бирегез. Стресс кичергәннән соң, алар тагын да ныгып китәргә мөмкин икән.

Сания ДӘҮЛИЕВА. Мамадыш

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

ПЕСИ БЕЛӘН БАЛА НАМАЗНЫ БОЗМЫЙ

Исламның икенче баганасы булып торган намазга бәйле бик күп сораулар бар. Әйтик, казага калган намазны ничек укырга? Ир белән хатын намазны бергә укырга тиешме? Намазлыкка песи килеп ятса, гыйбадәтне туктатыргамы?

Бу һәм башка сорауларга җавап эзләп, «Әл-Мәрҗани» мәчетеннән Айморат хәзрәт ХАҖИЕВКА мөрәҗәгать иттек.

– Бисмилләһир-рахмәнир-рахим! Пәйгамбәребез (с.г.в.) үз хәдисендә әйтүенчә, Адәм баласы Аллаһы Тәгалә каршына баскач, иң беренче чиратта гамәлләре белән җавап бирәчәк. Намаз да соралачак. Шуңа да намаз уку мөселман булган кешегә фарыз. Кеше дингә килгәндә, аны өйрәнә башлаганда, фарыз булган гамәлләрне акрынлап өйрәнергә тиеш. Барысын да берьюлы өйрәнә башласа, кешегә авыр булырга мөмкин. «Хәзрәт, болай булмый, барысы да тиешле, таләп ителгән...» – дип борчылып мөрәҗәгать итүчеләр дә бар. Әмма Аллаһы Тәгалә дә әйтә: дингә җиңел итеп, ягымлы итеп чакырырга кирәк. Ислам дине катлаулы, диләр. Юк, ул бик җиңел.

:: Намазлыкка песи килеп ятса яки сабый килеп утырса, намазны өзеп, кабат укырга кирәкме?

– Кечкенә балалар намазны бозмый. Гыйбадәтне яңадан башларга кирәкми. Шулай ук песи дә намазны бозмый. Ул нәҗес хайван түгел. Ягъни ул пычрак хайван саналмый. Намазлыкта, киемдә йоклап ятуы да пычратмый. Намазны дәвам итәргә мөмкин.

:: Бер намаз вакыты чыкканда анысын укып, вакыты керүгә, шундук икенче намазны укырга ярыймы?

– Бу бик үк дөрес түгел. Бу хәйлә булыр. Коръәндә дә әйтелә: «Дөреслектә, мөэминнәр өчен намаз үз вакытында язылган». Намаз уку календарьлары бар. Намаз вакытлары билгеләнгән. Әлбәттә, Аллаһы Тәгаләнең әҗер-савабына ирешергә теләсәк, һәр намазны вакытында үтәргә тиешле без. Әйтик, иртәнге намазны һәм өйләне ничек кушып укырга кирәк? Мосафир кешеләр өчен, әлбәттә, бер намаз чыкканда икенчесен уку (әйтик, ахшам белән ястү) рөхсәт.

:: Намаз укып утырган кешенең алдыннан узып китәргә ярамыймы?

– Бу динебездә хупланмый, бик үк хәерле гамәл түгел. Хәдистә: «Әгәр намаз укучының алдыннан чыгучы моның нинди гөнаһ икәнен белсә, 40 вакыт көтеп торуны хәерлерәк күрер иде», – диелә. Намаз укучы алдыннан узучылар гөнаһлы булмасыннар өчен, пәрдә кору (ситра) хәерле. Йә урындык, йә пәрдә, нинди дә булса объект.

:: Намаз укыганда кыска дога урынына «Аятел көрси» укырга рөхсәтме?

– Намазда укылырга тиешле аять, сүрә, догалар бар. Адәм баласы, өйрәнгәнче, ул догаларны белми икән, башкаларын укып торса хәерле. «Мин белмим», – дип кенә ярамый. «Аятел көрси»не «Фатиха» сүрәсеннән соң укырга мөмкин, әмма аерым дога буларак – юк.

:: Ашыкканда намазны ничек итеп укырга?

– Динебездә ашыгу хупланмый. Ашыгу ул – шайтаннан. Намазны эчке ышану белән, җиренә җиткереп, тыныч кына уку тиешле. Намазны ашык-пошык уку – мәкруһ, хупланмый торган гамәл. Әмма Адәм баласы бик ашыга, әйтик, ниндидер җитди эше бар икән, намазны сөннәтләрсез, тәсбихларсыз гына укырга рөхсәт ителә.

:: Ир белән хатын намазны бергә укырга тиешме?

– Һәрбер җирдә дә хатын-кызга да, иргә атка да аерым урыннар бар. Гаилә булып саналган ир белән хатынга исә бергәләшеп намаз укырга ярый. Шулай ук балалары – кыз һәм малайлары белән бергә укырга мөмкин.

:: Намазны казага калдыру тәртибен һәм аны үтәү турында аңлатсагыз иде. Күпләр, намазны җыеп укысаң да ярый, диләр бит.

– Көн дәвамында намазларны туплап, аларны кичкә генә җыеп уку – гөнаһ. Аллаһы Тәгаләнең вакытында укырга кушуына каршы килү бу. Шуңа күрә, белә торып, ялкауланып казага калдырып, аннары барысын да җыеп уку дөрес түгел. Әйткәнемчә, дингә әле генә аяк баскан кешеләргә, намаз укырга акрынлап тотынырга, бишесен дә вакытында үти башларга өйрәнергә кирәк.

– Намаз вакыты кереп, кул астында су булмаганда, тәһарәт алу өчен дымлы тастымал (влажные салфетки) кулланырга ярыймы?

– Намаз укуның төп шартларының берсе – тәһарәтле булу. Иң элек без чиста су белән тәһарәт алабыз. Дымлы салфетканың исә исе дә булырга мөмкин, тиешенчә дымлы булмаска да мөмкин ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Июнь аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Пәнҗ	01:07	03:07	17:23	20:16	21:46
2	Җом	01:06	03:06	17:24	20:17	21:47
3	Шим	01:05	03:05	17:25	20:18	21:48
4	Якш	01:04	03:04	17:26	20:19	21:49
5	Дүш	01:03	03:03	17:26	20:21	21:51
6	Сиш	01:02	03:02	17:27	20:22	21:52
7	Чәрш	01:01	03:01	17:28	20:23	21:53
8	Пәнҗ	01:01	03:01	17:28	20:24	21:54
9	Җом	01:00	03:00	17:29	20:25	21:55
10	Шим	01:00	03:00	17:29	20:26	21:56
11	Якш	00:59	02:59	17:30	20:27	21:57
12	Дүш	00:59	02:59	17:30	20:27	21:57
13	Сиш	00:58	02:58	17:31	20:28	21:58
14	Чәрш	00:58	02:58	17:31	20:29	21:59
15	Пәнҗ	00:58	02:58	17:32	20:30	22:00
16	Җом	00:57	02:57	17:32	20:30	22:00
17	Шим	00:57	02:57	17:32	20:31	22:01
18	Якш	00:57	02:57	17:33	20:31	22:01
19	Дүш	00:57	02:57	17:33	20:31	22:01
20	Сиш	00:57	02:57	17:33	20:32	22:02
21	Чәрш	00:58	02:58	17:33	20:32	22:02
22	Пәнҗ	00:58	02:58	17:34	20:32	22:02
23	Җом	00:58	02:58	17:34	20:32	22:02
24	Шим	00:58	02:58	17:34	20:32	22:02
25	Якш	00:59	02:59	17:34	20:32	22:02
26	Дүш	00:59	02:59	17:34	20:32	22:02
27	Сиш	01:00	03:00	17:34	20:32	22:02
28	Чәрш	01:00	03:00	17:34	20:32	22:02
29	Пәнҗ	01:01	03:01	17:34	20:32	22:02
30	Җом	01:02	03:02	17:34	20:31	22:01

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Гыйбрәт ал!

«ТАШ ҖЫЕП АЗАПЛАНМЫЙМ!»

Авыр хәрби өйрәнүләрдән кайтып килүче гаскәр, зур тау янына килеп җиткәч, ял итәргә туктый. Алар әмирләренә:

– Юлыбызны дәвам итәр өчен, шушы галәмәт биек тауга менәсе буламы? – ди.

– Юк, – диде әмир. – Юлыбызны дәвам итәр өчен, туннель аша шактый озын араны узарга кирәк. Ахыргы боерыгым исә шул булыр: туннель аша чыкканда аяк астындагы ташларны җыеп, юл капчыгына тутырырга. Аңлыйм, ул – өстәмә авырлык, ләкин ташларны мөмкин кадәр күбрәк җыегыз!

Туннельгә керүгә, ир-егетләр аптырап калдылар: монда кап-караңгы! Юлны караңгыда дәвам иттеләр.

Намуслы, җаваплы солдатлар юл капчыкларына таш тутыра башладылар. Авыр булса да, боерыкны үтәделәр. Икенчеләре бераз җыйганнан соң: «Әйдә, интегеп, авыр күтәреп йөрмим әле», – дип, кем ярты капчык, кем өчтән берен генә тутырып, таш җыюдан туктадылар. Өченчеләре исә ташларны бөтенләй җыймады.

Алда 30 чакрымлы туннель юлының ахырын билдерүче яктылык күзгә шәйләнгәч, барлык хәрбиләр дә сөенде.

Менә, ниһаять, туннель бетеп, солдатлар якты дөньяга чыктылар. Җете кояш нурлары күзләрне камаштырганга күрә, ирләр беравык берни күрмичә тордылар. Бераз иялнгәч исә, күз карашлары аяк киемнәренә ябышкан ташларга төште: бу затлы асылташлар иде.

– Караңгы туннель эчендә бик кыйммәтле асыл ташлар булганын белдем мин, – диде хәрбиләр әмире. – Бу капчыкларыгыз үзегезгә кала, рәхим итеп, өйләрегезгә алып кайтып китә аласыз.

Шуннан соң барлык солдатлар, кабаланып, капчыкларын ачып карады: анда нинди генә таш юк! Һәр хәрби шулай итеп үзе башкарган эшнең әҗерен үзе күрде.

(Ришат хәзрәт Курамшинның социаль челтәрдәге шәхси сәхифәсеннән алынды)

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА.

И туган тел, и матур тел...

Мин = милләт

Асыл

ХЕСЕЛ ГАРЛЫЕВА, ТӨРЕКМӘН, 21 ЯШЬ

Читтә белем алырмын дип уйламадым да. Казанга килгәч, бу шәһәрнең чынлап та күпмилләтле булуына игътибар иттем. Туган як сагындырды, иялэшү кыен булды. **ӨЙДӘН ЧИТТӘ ТУГАН ТЕЛЕМДӘ ЖЫРЛЫЙ АЛМАМ, УЕН КОРАЛЛАРЫНДА УЙНАРГА МӨМКИН БУЛМАС ДИП УЙЛЫЙ ИДЕМ.** Әмма ялгышканмын!

Гаиләмдә традицияләр саклана һәм тиешенчә үтәлә. **БЕЗНЕҢ ӨЙДӘ БАРЫСЫ ДА АНА ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШӘ.** Әти-әниләр балачакта үз телебезне бозып һәм хаталар ясап сөйләшергә **РӨХСӘТ ИТМӘДЕ**.

Үз телеңне белмичә, башка телләрне өйрәнәм димә. Минемчә, **ТЕЛ УЛ – ИХЛАСЛЫГЫҢНЫ ҺӘМ ҮЗЕҢНЕ КҮРСӘТҮ ЧАРАСЫ ДА**.

Төрекмәннәр – дөньякүләм танылган халык. **МИН АТА-БАБАЛАРЫМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАМ.** Алар бик күп фәннәргә нигез салган. Безнең милләт вәкилләре хәзерге заманга кадәр үз гореф-гадәтләрен **САКЛАП КАЛА АЛГАН.**

Тел дигән байлыкны балаларыма да тапшырасым килә. Моның өчен аларда **КЫЗЫКСЫНУ УЯТЫРГА** кирәк. Моны **ИЖАТ** аша, **ЖЫРЛАР, КӨЙЛӘР** аша эшләп булыр дип уйлыйм.

Киеем, ижат итәм, камилләшәм – болар барысы да милләтем өчен! **ЧИТ ШӘҺӘРДӘ МИН ВАТАНЫМНЫ ТАГЫН ДА КҮБРӘК ЯРАТА БАШЛАДЫМ.** Россиядә дүрт ел яшәп, халкым турында тагын да күбрәк белдем. **ТАТАРСТАНГА ДА РӘХМӘТ:** ул мине милләтемне һәм үземне сөяргә, хөрмәт итәргә өйрәтте.

Хесел – Казан федераль университеты студенты. Тарих факультетында белем ала. Барлык ижади чараларда аны милли уен коралы белән күрергә мөмкин, моңлы итеп жырлый да. Модель дә әле үзе!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Фото: Анна АРАХАМИЯ

31 май | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ». Телесериал 16+
10.00, 23.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». Телесериал (Россия) 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «БОМБА». Телесериал (на татарском языке) 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым» 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» 0+
15.45 «Татар сүзе» 6+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
Билгеле булганча, бүген аборт мәҗбүри медицина иминиятләштерүе полисы буенча бушлай күрсәтелә торган медицина хезмәтләре рәтенә керә. Россия Дәүләт Думасы депутатлары аны шушы исемлектән алып, бала төшертүне түләүле ясарга тәкъдим итә. Проект авторларының берсе – депутат Виталий Милонов фикеренчә, бүген Россиядә абортлар санын киметү өчен күрелгән чаралар җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Яңа тәкъдимгә исә зур өметләр баглый алар.

Татарстан сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин фикеренчә, абортларны түләүле итү белән беррәттән, шәхси медицина оешмалары эшен дә контрольгә алырга кирәк. Яшеренбатырын түгел, бүген бала төшерү очракларының күбесе нәкъ менә шуларда ясала.

– Дәүләт дәвалау оешмаларында хатын-кызны аборт ясату ниятеннән кире кайтарырга тырышалар. Безнең һәр хатын-кыз консультациясендә махсус кабинет эшли. Әгәр хатын-кыз, кыен хәлдә калып, аборт ясатырга җыена икән, аның белән иң беренче чиратта психолог эшли. Аңа уйларга бер атна вакыт бирелә. Шуннан соң гына ахыргы карар кабул ителә. Ә хатын-кыз, шушы бер атна эчендә шәхси клиникага барып, бернинди киртәләрсез аборт ясата ала. Аны анда колач җәеп каршы алачаклар. Чөнки шәхси клиникалар өчен аборт – иң беренче чиратта керем чыганагы. Алар әле баланы төшертеп кенә калмыйча, йөккә уза калсаң, тагын кил, дип озатып та калырга мөмкин. Бу очракта иң куркынычы шул: без статистиканы тулысынча күреп бетерә алмыйбыз. Шәхси клиникаларда күпме аборт ясала? Шуңа күрә дәүләт оешмалары белән шәхси клиникалар арасында элемтә, мәгълүмат алмашу булырга тиеш, – дип саный министр.

Хатын-кыз консультациясендә алып барылган аңлату эшләренең нәтиҗәлелеген саннар да дәлилли.

> Узган ел, анда эшләүче табибларның киңәшләренә колак салып, 44 меңнән артык хатын-кыз аборт ясатмаска булган. Ел дәвамында исә Россиядә барлыгы 400 меңнән артык бала төшертү очрагы теркәлгән. Соңгы ун елда илдә аборт ясату очраклары ике тапкыр диярлек кимегән. Татарстанда узган ел барлыгы 12,5 мең аборт ясалган. Шуларның яртысы – хатын-кызның сәламәтлеге начар булу аркасында, тагын шуның кадәре – хатын-кызның үз теләге белән.

vk.com

Яңа закон проекты соңгысын киметүне күздә тота да инде. Шулай да Татарстан Иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Татарстанның күпбалалы гаиләләре» төбәкара иҗтимагый оешмасы рәисе Артем Кузнецов бу үзгәрешнең уңай нәтиҗә бирәчәгенә шикләнеп карый. Аның фикеренчә, безнең илдә нәрсәнедер тыю белән генә бернигә дә ирешеп булмый.

– Абортларны түләүлегә калдырсалар, илдә законсыз рәвештә бала төшертү очраклары артачак. Өстәвенә бүген җәмгыятьтә «тәнем үземнеке, нәрсә телим, шуны эшлим» дигәнрәк караш яшәп килә. Абортларны кисәтү өчен, гаилә сәясәтен ныклабрак алып барырга, балаларга кечкенәдән үк «гаилә кыйммәтләре» дигән төшенчәне сеңдерергә кирәк. Моның өчен мәктәпләргә совет чорындагы кебек гаилә нигезләре дәресен кире кайтарырга кирәк. Анда гаиләнең рухи кыйммәтләреннән башлап интим мөнәсәбәтләргә кадәр барысы да җентекләп аңлатылса, илдә аборт ясату кебек үкенечле хәлләр дә сирәгрәк күзәтелер иде, – дип саный ул.

Тәнкыйтьләргә ашыкма

Илкүләм халык фикерен өйрәнү үзәге уздырылган шундый ук сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Россиядә яшәүче өч хатын-кызның берсе (29%) бер тапкыр булса да аборт ясаткан. Моннан җиде ел элек уздырылган шундый ук сораштыруда болай дип җавап бирүчеләр саны өч тапкыр кимрәк булган. Шунысы да бар: вакыт аралыгында илдә бала төшертүгә каршы булучылар саны 4 проценттан 13 процентка җиткән.

Казан федераль университеты клиникасындагы акушерлык бүлегенең югары категорияле акушер-гинекологы, медицина фәннәре кандидаты Резедә Шәрипова фикеренчә, аборт ясатырга карар кылган хатын-кызны тәнкыйтьләргә ашыкмаска кирәк.

– Аборт ясатырга килүчеләр арасында төрле яшьтәге хатын-кызлар очрый. Һәркайсының моңа үз сәбәбе бар. Көчләү кебек куркыныч күренешләр дә еш очрый. Мондый хәлгә юлыккан хатын-кыз, әлбәттә, иң беренче чиратта көмәненнән котылырга теләячәк. Без хатын-кызларның күбрәк бала табуын, бала төшертү очракларының кимүен телибез, билгеле. Әмма хатын-кызның сайлау хокукы да булырга тиеш, – ди белгеч.

Хатын-кызның үз теләге белән ясала торган абортларның тамырына балта чабарга тырышуларны да ике яклы пычак дип саный ул. Бер яктан, илдә туучылар саны елдан-ел кими бара һәм бу демографик упкынны башкача бетерү мөмкин дә түгел кебек. Икенче яктан, абортларны тулысынча түләүле итү белән илдә баласыннан халык медицинасы ысуллары, идән астыннан эш итеп ятучылар ярдәме белән котылырга маташучылар саны да артырга мөмкин, дип фаразлый белгеч. Ә монысы икеләтә куркыныч.

– Илдә бала төшертү очраклары кимесен дисәк, иң беренче чиратта, халыкның, бигрәк тә балаларның сексуаль белем дәрәҗәсен арттырырга кирәк. Балаларга җенси мөнәсәбәтләрнең асылын өйрәтергә, моны пропагандаларга кирәк дигән сүз түгел бу. Аларга бу күренешне куркынычсыз итүнең әһәмияте, контрацепция чаралары турында аңлатырга кирәк. Ата-аналар да баласы белән андый темага сөйләшергә оялмасын иде, – ди Резедә Шәрипова.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Фикер

Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН, «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы:
– Динебез абортны ананың гомеренә куркыныч янаган очракта гына ясарга рөхсәт итә. Калган очракларда аны ясау кеше үтерү белән бер дәрәҗәдәге гөнаһ санала. Һәр бала үз ризыгы белән туа. Шуңа күрә нинди генә хәлдә калсаң да, баланың гомерен саклап калырга тырышырга кирәк. Корьәни Кәримдә дә: «Шайтан сезне ачлык белән куркытыр. Ләкин белегез: ризыкны бирүче шайтан түгел, ризыкны бирүче – Раббыбыз Аллаһ», – диелә.

«ӨЧ ЕЛДАН ДА БЕЛЕНӘ»

Аборт хатын-кыз организмына ничек тәэсир итә? Аннан соң кабат йөккә узып буламы?

Шул сораулар белән Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш репродуктологы Фирая САБИРОВАга мөрәҗәгать иттек.

:: Аборт хатын-кыз организмында нинди эз калдыра?

– Бала төшерткәннән соң, организмда ялкынсыну башланырга, кан китәргә мөмкин. Бу адымга барган хатын-кыз, андый хәлләр күзәтелмәгән икән, димәк, бар да яхшы узган, аборт организмга бернинди зыян салмаган, дип уйлый. Кызганыч, бу алай түгел шул. Абортның тискәре нәтиҗәләре бала төшерткәннән соң ике-өч ел вакыт узгач та килеп чыгарга мөмкин. Аналыкның лайлалы тышчасы зарарлану аркасында, аңа кысырлык куркынычы яный. Эндокрин системасы эшчәнлеге дә бозылырга мөмкин. Ник дигәндә, аборт ясаганда, гормоннарга зур зыян килә. Болар берсе дә эзсез калмый. Шуңа бәйле рәвештә бала төшерткән хатын-кызның матдәләр алмашы, күрем циклы бозылырга, гәүдә авырлыгы кимергә мөмкин. Аборт салган психологик яра исә барыннан да авыррак.

:: Әле бер тапкыр да бала тапмаган хатын-кыз аборт ясатса, ул киләчәктә әни була алачакмы?

– Аборт ясаганда кулланылган заманча ысулларның организмга зыяны азрак. Шуңа күрә бала төшерткән хатын-кыз еш кына кабат йөккә уза ала.

:: Соңгы арада сезгә мондый мөрәҗәгать белән килүче хатын-кызлар саны арттымы, кимедеме?

– Бәхеткә, соңгы елларда бала төшертү очраклары кими бара. 1990 нчы еллар белән чагыштырганда, мондый күренеш ике тапкыр кимеде, дип әйтергә була. Бүген хатын-кызларның күбесе үз сәламәтлеген ныклап кайгырта, контрацепция чаралары куллана. Шулай да абортлар әле дә күзәтелә. Аны, гадәттә, инде бер тапкыр бала тапкан хатын-кызлар ясата. Икенче-өченче йөклелеген өзүчеләр шактый һәм бу борчуга сала. Ник дигәндә, алар инде яшь-җилкенчәк түгел, шуңа саулыкларына салкын караулары аңлашылып бетми. Форсаттан файдаланып, гүзәл затларга мөрәҗәгать итәсем килә: бала тапкач ук, табиб белән саклану чаралары турында киңәшләшергә кирәк. Юкса бала тапканнан соң күреме кабат килә башламаган килеш тә яңадан йөккә узып куючылар шактый.

:: Ничек уйлыйсыз: абортларны бушлай ясамый башласалар, бала төшертү очраклары кимерме икән?

– Абортларны тыю мәсьәләсендә андый рухтагы талпынышлар безнең илдә моңа кадәр дә булгалады. Аларның ни белән тәмамланунын яхшы беләбез. Ул, иң беренче чиратта, криминаль абортлар саны артуга китерә. Бу исә – сәламәтлеге какшаган, бала төшертү аркасында гомере өзелгән хатын-кызлар саны да артачак дигән сүз. Шуңа күрә абортка кагылышлы законны кабул итүләренә каршы мин. Илдә бала төшертүләр саны кимесен өчен, контрацепция чараларын пропагандаларга кирәк. Хатын-кыз баланы калдырыргамы-юкмы дип түгел, йөккә узаргамы-юкмы дип уйларлык булсын.

АТА ХАКЫ

БИШ БАЛАЛЫ РӘШИТ ЗИННӘТУЛЛИН ЯЛГЫЗ КАЛГАН

66 яшен тутырган Рәшит Зиннәтуллинның язмышы берәүгә дә битараф калдырмагандыр, мөгаен. Гаиләсе ташлаган, Казанның бер хастаханәсендә дүрт көн буе ярдәм көтеп утырган ир-ат бүген «Кеше приюты»нда яши. «ВТ» журналисты Рәшит абыйның үзен күреп сөйләште, аның үтенече буенча гаиләсенә барды, туганнары белән очрашты.

Өйдән приютка – 4 көн

Рәшит Зиннәтуллин йөри алмый, кеше ярдәменә мохтаҗ. Хастаханәгә аны хатыны китерә. Тик аннары килеп алучы кеше булмый, ә ул үзе кайтырлык хәлдә түгел. Дүрт көн буе коляскада утырган килеш, хастаханә коридорында якыннарын көтә. Хастаханә хезмәткәрләре гаиләсенә ничә тапкыр шалтыратса да, җавап бирүче булмаган. Дүртенче көнне аны блогер буларак күпләргә таныш Алия Хәлиуллина күреп ала. Ире белән Рәшит абыйны «Кеше приюты»на илтә. Бу хәлне Алия интернетка чыгаргач, битараф булмаган кешеләр ярдәме белән, Рәшит абыйга дип, 1 миллион сумнан артык акча да җыелар.

Рәшит абыйны приютта юындырып, чиста киемнәр бирәләр, йокларга урын табалар. Анда яшәвенең өченче көнендә аның янына без дә кердек. Кечкенә генә гәүдәле бабай икән. Бер ялгансыз, әле аның яшендәге кайберәүләрне алай дип атап булмаса да, Рәшит абый нык таушалган.

– Мин Ташкентта туып-үстем. Казанга күченеп килгән кеше. Мәчеттә дә эшләдем. Намаздамын, күп догалар беләм. Хатыным белән законлы язылышмадык без, никах белән яшәдек. Ике кыз үстердек. Рәнҗетеп яшәмәдем дә кебек. Аңлаша идек. Нигә болай булгандыр?.. Алар мине чыгарып ташламаган инде. Хатыным: «Хәзер киләм», – дип киткән иде, – дип сөйли үзе тыныч кына.

Шактый сөйләшеп утыргач, ул үзенең әманәтен җиткерде:

– Балам, сине Аллаһы Тәгалә минем янга җибәргән бит. Зинһар, гаиләм янына барып кайт әле. Хатынымның хәлен бел әле. Ул бит, киләм, дигән иде. Шикәр чире белән тилмерә ул, комага китеп ятмыймы икән? Исән-

Рөстәм Гыйльманов

«Ризык алырга да мөмкинлегем юк», – ди Зөлфия.

Зөлфия Хәлиуллина

Рәшит абый әле дә өенә кайтырга өметләнә.

сау булса, мине эзләр иде ул. Әгәр килеп алса, өйгә кайтыр идем. Соңгы өметем бу минем. Барып кына кайт, кызым!

«Минем ирем юк!»

Ул төнне йоклап булмады. Рәшит абый биргән адрес буенча барып та, мине кертмәсәләр, нишләрмен? Иртән, тәвәккәлләп, юлга кузгалдым. Килүен килдем, әмма домофоннары эшләми булып чыкты. 10лап күршегә баса торгач, бер мәрхәмәтлесе ишекне ачты. Кирәкле фатирга керү дә җиңел булмады. Кыңгыраулары юк, күпме шакып та ишек ачмыйлар. 30 минутлап ишек каккаЛнан соң, куркып кына ачып карарга булдым. Баксаң, бикләнмәгән дә икән! Эндәшүемә, бер хатын тавыш бирде. «Рәшит абыйның хатынымы сез?» – дип сорагач, «Минем ирем юк! – дип кычкырды. – Рәшит абый (иренә шулай әйтә икән. – **Г.Ш.**) белән никахлашып кына тордык. Без язылышмаган. Бу – минем фатир, ул йортка гына кергән иде».

Иплэп кенә сөйләшә торгач, Зөлфия тынычланды. Иреннән баш тартуының сәбәбе ару икән.

– Миңа кирәк түгел ул. Кызларыма да, – диде ул, кырт кисеп. – Дөрес, алар икесе дә әтиләре фамилиясендә. Олысы Рәйхан эшли. Үз акчасын үзе тота, аның әтисе артыннан йөрергә вакыты юк. Алдан ук әйтеп куйды. Кечесе Хафизәгә – 19 яшь кенә әле. Ул көллияттә укый, студент. Әтисе белән маташырга аның да вакыты юк. Рәшит абыйның өченче хатыны мин. Беренчесеннән улы Рәүф бар, икенчесеннән тагын ике баласы, миннән ике. Тормышта төрле чагы булды. Мәчеттә хәзрәт булып та торды. Әмма вакыт-вакыт эчеп ала иде. Рәнҗетте дия алмыйм. Мин ардым. Тормыш алып бару бик авыр. Рәшит абый егылды ул. Берничә мәртәбә имгәнде. Минем дә гаеп бардыр инде, карап та өлгермәгәнмендер. Урында ятуына дүрт ел булды. Шул вакытта Аллаһы Тәгалә хакына түздем, карадым, юындырдым. Хәзер булдыра алмыйм. Үз хәлем – хәл.

«Үз хәлем – хәл», – диюе арттыру түгел иде бугай, чыннан да, авыру, хәлсез ул. 50 яшьтә генә булса да, шактый өлкән күренә. Фатирда ир-ат кулы да, хатын-кыз кулы да җитмәгәне сизелә. Кыскасы, бар да акча җитмәүгә килеп тоташа.

– Рәшит абый 10 мең сум пенсия алды. Шуның 2 меңенә психотерапевт язган даруны ала идек. Зурларга дигән памперс 3 мең сум тора. Икебез бүлеп, квартплата белән газ өчен түләдек. Ул 3 мең сум бирә, мин 3 мең кушам. Ашарга да кирәк. Үзем дә ике яшемнән бирле шикәр авыруы белән яшим. 48 ел буе гел даруда яшәп кара син! Икенче группа инвалидмын. 12 мең сум пенсия алам. Кече кызым студент булгач, аны да ашатам. Дөрес, ул кирәк-ярагына укудан соң эшләп акча таба. Бөтен әйбер кыйммәт бит. Кибеткә дә айга өч кенә чыгам мин. Көнгә ике тапкыр гына ашыйм. Квартплатаны хәзер өчкә бүлдерергә җыенам. Кызларым да түләшсен, дим. Берүземә авыр бит, – ди ул.

Ни өчен илткәннәр?

Рәшит абыйның бер ай элек уң кулы эшләми башлаган.

– Кулы эшләми башлагач, мин аны дәваларга кирәк дип уйладым. Хастаханәгә илтүче «санитар ярдәм» дигән хезмәт бар икән. Шуларга шалтыраттым. Ике егет килеп, Рәшит абыйны алып киттек. Башта неврология хастаханәсенә алып бардык. Андагылар: «Без дәвалый алмыйбыз, башка җиргә барыгыз», – диделәр, – ди Зөлфия. – Икенчесенә килдек. Тик анда безне кабул итмәделәр. «Ашыгыч ярдәм» алып килгән кешеләрне алалар, безне юк. Озак көттек. Инде нишләргә, дим. Өйгә кире алып кайтмаячагымны беләдем инде. Алып килгән өчен дә 3 мең сум акча алдылар. Су алып киләм дип чыгып киттем.

– Өйгә кайткач, йөрәгегезгә авыр булмадымы? – дип сорап куйдым. Ни дисәң дә, 25 ел гомер иткән ир бит!

– Юк. Мин аны карый алмыйм. Шикәр чирен ничек дәвалыйсын беләм мин, ә менә аның авыруларын белмим. Медицина оешмасында ташламаслар әле, дидем. Урамда калмады бит, – диде Зөлфия. – Әти-әниемнән калган фатирда яшим. Бер туганым да юк. Рәшитнең туганнары күп аның. Карасыннар. Үлемткәкә дигән 15 мең сум акчасын сеңлесенә бирдем.

Биш бала һәм туганнар

Рәшит абыйның беренче хатыныннан туган улы Рәүф, Санкт-Петербургта яшәсә дә, әтисе турында ишеткәч, Казанга кайткан. Приютка да барган, әтисен дә күргән. Ярдәм итеп торасын әйткән. Икенче никахтан туган балалар турында бер хәбәр дә юк.

Без Рәшит абыйның Арча районында яшәүче туганнан туган сеңлесен эзләп таптык.

– Ишеткәч, Рәүф кайтты. Аның белән Казанга бардык. Рәүф картлар йортын да белешкән иде. Анда буш урыннар юк икән. Түләүле урыннар бар, дигәннәр. Безнең йортта Рәшит абыйны карар өчен шартлар юк. Рәшит абыйның өч ир туганы бар иде. Алар вафат инде. «Кеше приюты»на барып күрдек без аны. Анда яхшы карыйлар. Аерым бүлмәдә яшәячәк. Без андагы җитәкчеләргә дә әйттек: килеп йөреячәкбез, аны ташларга җыенмыйбыз, – ди ул. – Кулы эшләми башлагач, Рәшит абый имза куя алмаган. Хат ташучы, кул куймагач, пенсиясен бирмәгән. Әнә шул пенсиясе булмау аркасында чыгарып җибәрделәр дә инде өеннән...

Кемдер ялгышкан...

Рәшит абыйның якыннары белән сөйләшкәч, күңелдә күп сораулар туа. Беренче һәм икенче никахтагы балаларны аңлап була, алар әтиле килеш тә әтисез үскән! Ә соңгы никахтагы хатын һәм балаларны аңлый алмадым. Зөлфияне дә кызгандым әле мин. Бер кызы белән сөйләшүенең шаһиты булгангамы, аның картлыгы өчен дә борчылып куйдым. Кемдер кайдадыр ялгышкан... Балаларга ата-ана хакы турында сөйләргә онытканнар шикелле. Ир хакы да бар бит әле! Өйдәге бүлмәсен җыештырып, киемнәрен чүплеккә ташлап, үзен хастаханәгә илтсәләр дә, күңелләрендәге тапны юа алырлармы?..

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Фикер

Йосыф ДӘҮЛӘТШИН,
Кабан арты мәчете имам-хатыйбы:

– Әти-әнинең догасы бөтен кешегә кирәк. Ата-ананы рәнҗетеп, кимсетеп, бала үзенең тормышына авырлык китерә. Әле бит ахирәт тормышы да бар. Үзеңнең өлкәннәргә булган мөнәсәбәтең өчен җавап бирәсеңне дә онытмаска кирәк. Беркайчан да әти-әниеңә авыр сүз әйтергә ярамый. Алар сүзләрнең иң-иң матурларын гына ишетергә тиеш. Үзеңне үстергән ата-анадан ничек туярга була? Син кечкенә чагыңда калактан ашаткан, юындырган, киендергән якын кешеләрең үзләре олыгайгач, ягъни сабый хәленә килгәч, кирәксезгә әйләнә. Олыгаеп, алар күп күрә, күбесен ишетә, сөйләшә башлагач, балалары алардан тиз туя. Әмма җәннәтнең әти-әни аяк астында икәнен онытмыйк.

РУСЛАН ИБРАҺИМОВ:

«БЕЗГӘ ӨЛКӘН БУЫННАН ЕШ «ЭЛӘГӘ»

Талант дип без беркемне дә кабатламаган шәхесне атыйбыз. Рәссам Руслан ИБРАҺИМОВ та гадәти булмавы белән игътибарны җәлеп итә. Аның Тукае да, Вафирәсе дә, замандашлары да үзгә. Руслан – буяуны чәчрәтеп ясаучы рәссам-портретчы. IT парк диварындагы Бәшир Рәмиев, Казан кирмәнендәге Алтын Урда музее бизәлеше – аның хезмәтләре. Рәссам белән якыннан танышырга да вакыт җиткәндер, шәт.

Руслан Ибраһимовның шәхси архивыннан

:: Руслан, рәссамга яшәү җиңелме?
– Бер мизгелгә бу сорау миңа бик җиңел, гади кебек тоелды. Чыннан да, тормышбулмышым үземә ошый, димәк, яшәве дә җиңел. Ә тирәнрәк казына башласаң, башка төрле фикерләр килә. Яшәүнең җиңеллеге яки авырлыгы синең нәрсә белән шөгыльләнүеңә бәйле түгел. Күбрәк холкыңа бәйле. Әйтик, кайбер кешеләрнең тормышы җитеш, муллыкта яшиләр, әмма аларга гел авыр. Андый кешенең тынычлыгы юк, башында мең төрле уй, ул үзенә һәрвакыт борчу, проблема таба. Ә сәнгать, иҗат – камил дөньяга ишек (портал) бит ул. Шуңа күрә, иҗат иткәндә, борчу, проблемалар югала. Сәнгать синең бөтен тискәре энергияңне юып ала. Мөгаен, шуңа рәссамнар бәхетлерәктер.

:: Яшәү авыр булса, сәбәбен нидән күрәсең?
– Аның сәбәбе психологик җитлегүгә бәйледер. Әйе, кайчакта авыр була, әмма аңа мин үзем гаепле. Әйтик, каядыр барырга кирәк, ә мин бармый калам, нәрсәдер балактан тота. Карьера өчен ниндидер адымнар ясарга кирәк, ә мин тыелып калам. Шуннан үзең өчен сәбәбен ачыклап, үзеңне җиңәргә, алга барырга тырышасың. Элегрәк борчулар күп булды. Ул чакта, бәлки, мин бәхет өчен тумаганмын, дип тә җавап биргән булыр идем. Акрынлап яшь белән, тәҗрибә туплау бәрабәренә күңелдә тынычлык урнаша. Мин тормышымны иҗатка, рәсем сәнгатенә багышладым. Хатыным да минe рәссам булганга сайлады *(елмая)*.

:: Бер рәссам: «Танылу һәм баю өчен яһүд милләтеннән булырга кирәк», – диде. Килешәсеңме?
– Миңа калса, танылу өчен үзеңне кабул итү кирәктер. Ә калганнары алай ук мөһим түгел. Бездә шундый стереотип яши инде ул, имеш, татар булып дөньяга чыгып булмый. Рәссам ул – ярлы кеше, дигәне дә бар әле. Миңа мөһим түгел алар, үз фикерләрем, уйларым күпкә мөһимрәк.

:: Синең алымыңны, ягъни буяуны чәчрәтеп ясауны Татарстанда кабул иттеләрме?
– Татарстанда иҗатымны кабул иттеләр дип уйлыйм. Кешеләргә минем стиль, дөньяны кабул итү рәвешем ошый. Үземчә дөньяның, кешеләрнең эчке дөньясының матурлыгын күрсәтергә тырышам.

:: Татарстанның зур гына объектларының бизәлешендә катнашкансың икән. Әйтик, Бәшир Рәмиев исемендәге IT парк диварын бизәгәнсең. Андый эшкә алыну конкурс аша башкарыламы?
– IT парк өчен Бәшир Рәмиев портретын ясау бик үзенчәлекле заказ булды. Анда конкурс булмады. Архитектура компаниясе минем рәсемнәрне караган да, әлеге бина өчен шушы стиль кулай була, дип тапкан. Заманча, хайтек стиле дип әйтик. Мин дә килештем. Ул гына түгел, тагын бер объект бизәлешендә катнаштым әле мин һәм аның белән бик тә горурланам. Ул – Казан кирмәнендәге Алтын Урда музее. Аның ике диварында Алтын Урда образларын иҗат иттем.

:: Тукай, Нурихан Фәттах портретлары үзенчәлекле. Киләчәктә шушы юнәлештә эшләвеңне дәвам итәчәксеңме?
– Портрет юнәлешендә эшләүне үземнең миссиям итеп тоям. Булдыра алганнарның барысын да сурәтләп калдырасым килә. Бу – барыннан да бигрәк, татар шәхесләре. Мөгаен, күбрәк үземнең замандашларым портретларына алынырмын. Аларны тарихта калдырырга кирәк дип уйлыйм. «Ями мьюзик» төркемен, Эльмир Низамовны, Эльмира Кәлимуллина портретларын ясадым. Әле эшлисе эшләр бик күп.

:: Бер кызыкмы, кызганычмы хәлне сөйлим әле. Бер галимнең, синең башкарудагы Тукай портретын сатуда күргәч, хәтере калган. Беренчедән, син Тукайны буяуны чәчрәтеп ясап түбәнсеткәнсең, икенчедән, сатуга куеп. Өлкән яшьтәге абзый фикеренчә, Тукай сатылмый. Ни диярсең?
– Өлкән буынны мин бик хөрмәт итәм, киң карашлы фикерләренә колак салам. Әмма ул сыйфат барысында да булмый шул. Шуңа күрә, өлкән буынны тыңласаң, мәдәният алга китми, дигән фикердә ныграк торам. Хәзерге вазгыятькә килгәндә, мин бүгенге Татарстан вәкиле булуым белән бик горурланам. Заманча мәдәнияте бездә алга киткән. Рәдиф Кашапов, Мубай, Нурбәк Батулла, Йолдыз Миңнуллина… Минемчә, алар – генийлар. Һәм аларга олы буын вәкилләреннән гел «эләгә». Ләкин алар – безнең ышанычыбыз.

:: Иң зур хыялың нинди?
– «Дисней» кебек татар мегакорпорациясен төзер идем. Анда минем, гомумән, барлык милләттәшләремнең хыяллары чынга ашар иде. Мәсәлән, минем кино төшерәсем килә. Бу җәһәттән башта төрле уйлар, планнар бар. Мультфильмнар ясар идем, китаплар чыгарыр идем, комикслар.

:: Милли рәсем сәнгатендә иң зур проблема нинди?
– Иң зур проблема ул – милләт булмаудыр. Милли үзаңлы татарлар күп түгел. Заманча сәнгатьне дә бик аз кеше аңлый һәм күрә. Әйткәнемчә, Нурбәк Батулла – гений. Яшь килеш «Алтын битлек»кә лаек булган шәхес, иҗатчы. Әмма аның спектакльләренә кемнәр генә йөри соң? Бөтен Казаныңда бер йөз кеше бардыр иҗатын аңлаучы һәм шәхес буларак кадерләүче. Бәлки, ике йөздер… Милли заманча сәнгатьне аңлаучылар әнә шул кадәр инде ул. Ә калганнар үткәннәрдә яшидер төсле. Аларга баянда уйнау, милли биюләр ошый. Ә бит милләтне үстерергә кирәк. Үткәннәр белән генә яшәргә ярамый бит.

:: Казанда иң яраткан урының?
– Мөштәри урамы бик ошый. Ул калкулыкларда урнашкан, урам бер күтәрелә, бер түбән төшеп китә. Бик рәхәт урын.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

7 кызыклы факт

✓ Бәләкәй чакта мин күп чирләдем. Ел саен диярлек хастаханәдә ятып чыга идем. Кайсы елны берничә тапкыр дәваланырга туры килә иде.

✓ Беренче институтны тәмамлый алмадым, аннан мине беренче курсны тәмамлаганчы ук кудылар. Чөнки укырга теләк булмады. Анда архитектура юнәлеше булса да, күбрәк төзелеш өлкәсенә, инженериягә карый иде, ә миңа иҗат кирәк. Шуңа күрә икенче академиягә укырга кердем.

✓ Соңгы эшемнән киткәч, мин үземә беркайчан да беркемгә дә эшләмәскә рөхсәт иттем. Бер тапкыр гына шушы максатымны бозарга туры килде. Анысы да хыялымны тормышка ашыру өчен. Казанга күченер өчен дизайнер булып урнаштым. Казан минем хыялым иде. Ул эштә бер ел да эшләмәдем.

✓ Фатирдан фатирга күченгәндә, бер рәсемемне югалттым. Урладылар, ахры. Бәлкем, танылгач, бер килеп чыгар әле.

✓ Казанга күченгәч, энекәш белән туган телне яхшырак өйрәнү өчен, сөйләм клубы оештырдык. Аның оештыручылары, ягъни без татарча иң начар белүчеләр идек. Бу клубның икенче максаты да булды. Без анда фикердәшләрне таптык. Мин иң якын кешем – хатынымны очраттым. Шуннан соң клуб эшчәнлеге тукталды.

✓ Академиядә монументаль сәнгать бүлегендә укыдым, әмма ул юнәлештә эшләмәдем. Дөрес, дустым белән башта шушы юнәлешкә керешеп карадык, әмма ошамады. Ник дигәндә, син заказчыга бәйле, ә алар һәрвакыт ниндидер «отстой» тели. Монда хыялга бернинди мөмкинлек юк. Шуннан мин станок сәнгатен сайладым. Бер тапкыр гына, искиткеч заказ килгәч, алындым. Бу Алтын Урда музеен бизәү иде. Анда миңа тулы ирек бирделәр. Искиткеч булды.

✓ Бәләкәйдән атлар ярата идем. Мин үскән Себер шәһәрендә атлар бөтенләй юк. Шуннан миңа аларны ясарга туры килде. Атлар белән хыялланып, күп итеп ясагач, сан сыйфатка әйләнде.

< Ахыры. Башы 19 май санында

Ландыш Әбүдәрова

ОЛАБЫЙ

– Менә, безнең авылга кайтучылар булса, шуларга ияреп кайтырбыз. Син дә безгә кайтырсың, кунак булырсың, анда бөтен кешегә дә урын җитәрлек, – дип, үзенчә юатып булды.

Төн әнә шулайрак үтте.

Икенче көнне үк Муса агай, әбине машинасына утыртып, аның туганнарын, йә булмаса торган җирен эзләп китте. Иртә белән Җиһанын уятмас өчен өй ачкычын үзе белән алса да, чакырылмаган кунак белән кайткач, дәшми булдыра алмады. Киңәш-табыш кирәк. Җиһан киңәше белән башлаган эшнең ахыры һәрвакытта да хәерле була – Муса агай моны әллә кайчан белә инде.

Иң элек әби утырган поезд килгән якка станцияләр буйлап йөреп чыгарга кирәк дип хәл иттеләр. Хәтер дигәне бөтенләй булмаса да, энә түгел, кеше кадәр кеше бит ул! Бәлки әле, кемнеңдер кадерлесеедер дә. Һичшиксез, шулай. Аны югалтучылар бардыр бу дөньяда. Һичшиксез, бардыр. Аларны эзләп табып, кулларына исән-сау килеш тапшырырга кирәк әбине… Һичшиксез, кирәк…

Беренче килгән җирләрендә үк машина туктауга, әби сикереп тә төште кая барасын төгәл белгән кеше кебек төенчеген култык астына кыстырып, артыннан сөйләп кебек вак-вак эзләр генә калдырып, туп-туры китеп тә барды. Муса агай бер мәлгә генә, дөрес килгәнбез, әбинең акыл хәтере бөтенләй булмаса да, аяк хәтере бар икән әле, дип сөенеп куйды. Әмма әби: «Әниләргә кайтабыз, көтә торгандыр инде, бу бала нишләп кайтмый йөри, дип ачулана торгандыр, безнең өй күперне чыккач та уң якта, өянкеләр астында», – дип сөйләнә башлауга, ялгышуын тиз аңлады. Икенче, өченче, дүртенче һәм тагын бик күп авылларда йөргәндә дә, нәкъ шулай итеп, күпер янындагы өянкеләр астында утырган өйне эзләде ул.

Ә Муса агай, ару-талуны белмичә, йөртте дә йөртте аны. Җиһан апа әбине сабыр гына кабул итте, тәрбияләп карады, иренә ничек тә ярдәм итәргә тырышты. Шәһәр газеталарын алып, югалган кешене эзләүчеләр юкмы дип караштырды, телевизордан эзләүчеләр игълан бирмәгәнме дип көтте. Ләкин якын-тирә авылларда әбине танучылар табылмады.

Кайвакытта ераккарак киткәндә, бик соңга калып кайтырга яисә куна калырга туры килгәндә, Муса агай Сёманың ай-ваена карамыйча үгетләп, аны үзе урынына төнге каравылда торырга күндерә иде. «Син нәрсә? Акылыңнан яздыңмы әллә? Сәлимыч белсә… Мин ул тәртип саклаучы дип атала торган кавем белән алышбирешне өздем, алардан ераграк йөрергә тырышам, ә син күрәләтә торып, мине шулар авызына илтеп тыкмакчы. Менә ни өчен кулга ияләштергәнсең икән син мине», – дип, бик карышса да, Муса агай күп сүзле дустының җаен тапты. «Сәлимычтан курыкма, андыймондый белә калса, үзем сөйләшермен», – диде. Тегесе: «Мин төнге салкында чыгып йөрергә тиешме?» – дип, тагын да бәясен күтәрә башлагач, Җиһан апа бәйләгән теге свитерны да салып бирергә туры килде. Сёма бик кызыга иде инде шуңа. «Кыш чыгарга әйбәт свитер, миндә мондый булса, салкыннарга эһ тә итмәс идем», – дип торып-торып мактап куя торган иде.

Иртән станция начальнигы эшкә килгәндә, гадәттә, Муса агай территорияне әйләнеп керергә чыккан була. Менә шул вакытта алар ерактан торып исәнләшә. Сёмага төнне исән-имин үткәреп, Муса агайга охшатып, ягъни чын-чынлап хәл-әхвәл белешеп исәнләшергә генә кирәк. Менә монысы аеруча катлаулы: аның Сәлимычта һичкайчан эше булмады, алар, гомумән, үзе әйтмешли, Евклид геометриясендәге ике параллель. Кырынып, юынып, чәчен алдырып килсә, килеш-килбәте ягыннан Муса агай белән бер-берсенә охшап торалар анысы. Аның каравылга гына кия торган кышкы курткасының изүен ачып, свитерның муенын да күтәребрәк куйса… Шулай иттеләр дә. Сәлимыч бер исәнләште – сизмәде бугай, ә икенчесендә шикләнепме, әллә Муса агайга берәр йомышы төшеп, сөйләшеп торыр өченме, туп-туры каравылчы янына килә башлады. Бөтен караклыкны, Сёма уйлаганча, дөньядагы бөтен явызлыкның башын шушы сукбайдан күргән станция начальнигының үзенә таба үтәли тишәрдәй булып карый-карый якынлашуын күргәч, ул йөз еллык теге фонарьларга карап: «Нигә фонарь булып тумадым икән?» – дип уйларга гына өлгерде. Эшнең нидә икәнен белгәч, ни гаҗәп – Сёма өчен бу гомерлек сер булып калачак – Азат Сәлим улы полиция чакыртмады, каршында үзен түгел, ә бик күп кагыйдәләрне, эш тәртибен, хәтта ки Хезмәт кодексын бозган Муса агайны намусын яклаган кебек очына-очына яклаган сукбайга бик озак итеп, сүзсез генә карап торды да шулай ук дәшмичә генә борылып китеп барды. Ә бераздан сукбайның бөтен дөньясының астын өскә китергән бер гаҗәп хәл булды. Ул инде сменасын тапшырып, Җиһан апага төннең тыныч узуы, станция начальнигының аны күреп тә, бер сүз әйтмичә китеп баруы турында түкми-чәчми хисап тотарга дип барырга җыенганда, аның янына идән юучы Мәликә түти килеп керде. Кулында бер стакан кайнар чәй белән ике телем түтерброд. «Сәлимыч бирде. Сиңа!» – диде ул, әйберләрен бәләкәй өстәлгә тезеп куйгач. Һәм «Ничек булгандыр бу хәл! Үзем дә берни аңламыйм!» дигәнне белдереп, гаҗәпләнүеннән кулларын җәеп җибәрде…

* * *

Озакламый Сёма, җылы курткасын тагын да ныграк бөркәнеп, муенын җылы свитерга ныграк батырып, Муса агайларга китеп бара иде. Ноябрьнең кышка авышканлыгын белдереп, уйнаклый-уйнаклый төшеп торган кар аның битенә, чәчләренә куна, әмма ул аларга игътибар итми, җил белән сөзешкәндәй, башын ия төшеп, йөгерә генә. Үзе күңеленнән генә Муса агайга Сәлимычның нинди әйбәт кеше икәнлеген сөйли. Ә Муса агайларда исә хәбәрнең тагын да олырагы көтә. Нинди хәбәр булсын инде – әбинең улы белән килене табылган иде.

Рүзәл Мөхәммәтшин

КЫСКА ЮЛ

(хикәя)

Аның каруы теш сызлавы бетте.

Яңактагы шеш кимемәгән әле. Учымны терәтәм – җылы бәреп тора. Кабарынкы иреннәрдән җан киткән. Тешләп карыйм – берни тоймыйлар. Авызда – ачкылтым дару, ватылган сөяк һәм оеган кан тәме.

Мине Кукмарага кайтарасы ПАЗдан иң элек таныш өн атылып чыкты:

– Ой-йо! Син түгелме соң бу?

Аннары Рүзәл тулаем күренде.

Без – авылдашлар, сыйныфташлар, дуслар һәм башкалар. Исемлекне әллә ничаклы тартып-сузарга мөмкин. Икебез дә тугызда укыйбыз. Урта рәттәге беренче парта күп дәрестә уртак максатка хезмәт итә. Әйтик, «Диңгез явы» уйнауга.

Безнең авыл ике төбәк чигендә урнашкан. Шуңадырмы, күрше Нократ Аланы шәһәренә (ягъни биргегә) барып кайтуны Толлы халкы абзар артын урап керүгә тиң күрә. Кыскасы, мондый очрашулар – гадәти күренеш.

– Йолкыдылар теге тешне, – дидем.

– Иң бәхетле чагың, алайса, – дип кызыкты ул.

– Аңламадым.

– Элгәреге газап та онытылмаган, шул ук вакытта инде бер җирең авыртмый да. Капма-каршы хисләр арасындагы искиткеч халәт.

– Без бәхетне төрлечә аңлыйбыз икән. Үзең нишләп йөрисең?

– Район газетасына барган идем. Гонорар бирделәр. Яңа телефон аппаратына җитәрлек.

– Сезнең телефон бар бит инде.

– Бусы минем бүлмәдә торачак. АОН белән. Кем шалтыратканын күрергә. Кызлар туда-суда булса, төребкәне үзем алачакмын.

– Шәп, – дидем, ПАЗ ишегенә үрелеп. – Йә, күрешкәнче!

Рүзәл моңа күзләрен акайтты:

– Иптәшкә бармыйсыңмыни?

– Автобус ун минуттан китә.

Ул тәкәллефсез генә сәгатенә бакты.

– Тугыз минуттан, – диде, аныклап. – Өлгерәбез.

Миңа бу тәкъдим ошамады. Ләкин мин ризалаштым.

Без кибеткә чаптык.

Борын төбендә светофорның кызылы янды. Гомернең утыз секунды каравыл кычкырып җан бирде. Барып җиткәнче тагын ике минутны әрәм иттек. Аннары ике минут телефон сайладык. Бер минут касса төбендә таптандык. Кайтыр юлга өч минут утыз секунд калган иде әле. Ягъни кирәгеннән артык. Борын төбендә янә светофорның кызылы янды. Ләкин бу юлы тукталып тормадык.

– Өлкәннәр сүзен тыңларга кирәк, – диде сыйныфташ. – Ә алар, һәрнәрсәнең чамасы булырга тиеш, дип өйрәтә.

Бәхеткә, автостанциягә төп-төгәл вакытында кайтып өлгердек.

Бәхетсезлеккә, автобустан барыбер җиләр искән иде инде.

Безнең бер дә көләсе килмәде.

– Расписаниене тәфсилләп карарга кирәк, – диде Рүзәл.

Ләкин расписаниенең тәфсилләп карарлыгы юк иде. Нократ Аланыннан Кукмара ягына, ягъни безнең район үзәгенә автобус кичке дүрттә генә юлланачак. Кукмарадан Толлыга, ягъни безнең туган авылга автобус иртәнге алтыда, төшке бердә һәм кичке биштә җибәрелә. Ягъни такси яллаcак, бердәгесенә җитешәбез әле.

– Син нәрсә, – диде дустым, исе-һушы китеп. – Син таксиның күпме торганын беләсеңме?

– Белмим, – дип дөресен әйттем мин.

– Ну вот.

– Күпме соң?

– Белмим, – дип дөресен әйтте ул да.

Ачыкладык: такси хакы җитмеш сум икән. Ун чакрымлык юл өчен кыйммәтрәк, билгеле. Ләкин мин моңа риза идем. Җитмәсә, ике кеше утыз биштән атышачак.

– Син нәрсә, – диде Рүзәл. – Акчаны кем шулай әрәм-шәрәм итә инде?

– Дүрттәгесен көтәбезме? Биштә Кукмарадан китә. Алтыга авылда булачакбыз.

– Юк, алай кичкә калына, – дип кырт кисте авылдаш. – Нишләргә?

Аңа утыз ике тешен күрсәтеп елмаерга ә дигән ара җитте.

Шулвакыт, искә төшеп, мин дә яңагыма орындым. Оюынган кызык табып, иренемне чәйнәп бетергәнмен. Хәзер, даруның көче беткәч, чи яра сулкылдап-әрнеп тора иде.

– Шәп! – диде Рүзәл, ниһаять. Ул, фикер очын югалтырга курыккандай, ашыга-кабалана сөйләде. – Нигә без Кукмара аша кайтырга алгысынабыз соң әле? Нократ Аланыннан Шөнгә кадәр автобус сәгать саен йөри. Киров өлкәсендә билет хакын үзең беләсең. Шалкан бәясе. Аларның Шөненнән безнең Толлыга кадәр өчдүрт чакрым ара. Кыска юлдан җырлап кына җәяү үтәрбез!

Миңа аның тәкъдиме ошамады.

Сул колакны уң кул белән кашып маташу кебек иде бу.

Шулай дип әйттем дә:

– Ярар.

Без автостанциядән билет алып чыктык.

Ул, чыннан да, бик арзанга төште.

Ишекне шап итеп ябуга:

– Слушай! – диде Рүзәл, «Эврика!» рухында. – Без җитмеш сум отышта калдык бит!

– Шуннан?

– Ул бит барыбер тотыласы акча иде.

– Шуннан? – дип кабатладым мин, пошаманга бирелеп.

– Әйдә, аңа берәр мәгънәле, яхшы нәрсә сатып алабыз.

– Мәсәлән?

– Мәсәлән, колбаса.

Һай, бу безнең балачак, үсмерчак. Туксанынчы еллар. Яңа гасыр башы. Тоташ юклык. Өстә – абыйлардан калган киемсалым. Кибеттән азык-төлек алу турында уйлау да юк. Үзебезнең бәрәңге. Ипи. Сөт.

Авыл белән шул хәл.

Ил белән үк, димәсәң.

Кыскасы, без, дәррәү куанышып, базарга чаптык.

Бу юлы, әлбәттә, бик тырышсаң да, автобуска һичничек соңарырга мөмкин түгел иде.

– Яшен ике тапкыр бер урынга сукмый, – дип куәтләде дустым.

Ләкин каһәр суккан ПАЗ табигать белеменнән искиткеч надан булып чыкты.

Колбасабызны тотып калдык.

Һәм алдагы илле минуты, урыныбыздан бер кар ышка да кузгалмыйча, тукталышта гына уздырырга сүз куештык…

Аның каруы көне гаҗәеп матур иде.

Салкынча язгы сафлык. Кытырыш кар өсте зеңләп тора. Анда, кызган табага баскандай, кояш нурлары сикеренә.

Март кояшы барыбер үзгәчә карый шул.

Яратып карый.

Һәр якта кошлар чыр-чуы. Күк шундый зур, шундый аяз! Чиста!

Өч-дүрт очкыч эзеннән кала очсыз-кырыйсыз киңлектә бер генә тап та, бер генә төртке дә юк.

Ахыры бар >

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

медицина тикшеренүе узу өчен **СЕРТИФИКАТ** уйната

2023 елның 5–15 июнь көннәрендә «Ватаным Татарстан» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 – җомга саны
444 сум 54 тиен
гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 –
атнага дүрт тапкыр чыга
1051 сум 80 тиен
гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~

1 **ЯЗЫЛ!** 2023 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына языл

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**

89179270040 info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘК ОТ!**

Сертификатлар:
1) 9 төрле УЗИ+уролог консультациясе;
2) 9 төрле УЗИ+гинеколог консультациясе;
3) остеопат ярдәме.

Тулырак сайтта: vatantat.ru

Акция 2023 елның 28 апреленнән башлап 30 июненә кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

МЦ «НУРМЕД»

«Сәламәт хатын-кыз»

*АКЦИЯ ~~5 100 сум~~ **3 100 сум**

Анализлар. Кече оча әгъзаларына УЗИ.
Сөт бизләренә УЗИ. Гинеколог консультациясе.

*Акция 2023 елның 30 маена кадәр дәвам итә.

(843) 246-76-00
(843) 209-19-29

Адрес:
Салих Батыев ур., 1 йорт

Тулырак сайтта: nhkrt.ru

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШҮ СОРАЛА.

Реклама 18+



Әз-мәз мәзәк

– Мин – табышмак хатын.
– Ә нәрсәдә чагыла бу?
– Әйтмим.

* * *

Бик күңелсез булса, зур тәрәзәле фитнес-клуб янына килеп, велотренажерда йөгерүче кешеләр каршында пәрәмәч ашарга мөмкин.

* * *

Трамвайда телефоннан талашучы кешеләр, сезгә әйтәм: тавышын көчәйтеп куегыз әле, тегеләр ни дип җавап бирә!

Да тыңлап карыйк та бит.

* * *

Метрода халык шыгрым вакытта иң зур кеше артыннан барыгыз.

* * *

Караоке бәйгесендә җиңәр өчен, матур тавышың булу гына аз. Әле хәреф танауның да кирәк.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: катык, ялкау, Идрис, бикәч, каеру, Анри, Наоми, таш, кап, бу, Тосно, Аскона, Карәми, абага, ит, Ра, Аддис, бире, Ык, Нафис, яра, бәрән, сугым, чигу, кәфен, сәнәк.
Вертикаль: кабартма, аш, Соб, Бәрәзә, Такташ, Ариф, Болгари, әче, кич, ун, Есенин, ак, яркәнат, сүс, Лиана, Охрид, ксерокс, янгын, Риман, Мисыр, уку, Ипполит, каймак.

Беләсең килсә...

1 Телефонны кем уйлап тапкан?
а) Александр Белл;
б) Томас Эдиссон;
в) Альберт Эйнштейн.

2 Гипертония нәрсә ул?
а) түбән кан басымы;
б) югары кан басымы;
в) йөрәк тибеше бозылу.

3 2000 елда Татарстан Язучылар берлеген кем җитәкләде?
а) Ринат Мөхәммәдиев;
б) Фоат Галимуллин;
в) Илфак Ибраһимов.

4 Тутый кош токымына исем биргән «лори» сүзе голланд теленнән ничек тәрҗемә ителә?
а) салават күпере;
б) пальма;
в) клоун.

Җаваплар: 1. а); 2. б); 3. б); 4. в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14266 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 273

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булырак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+